АВЫЛ КӨТӘ

«ВТ» хәбәрчесе хат эзеннән Актаныш районында йөреп кайтты

> 5

МӘКТӘПКӘ ЙӨРМИЛӘР

Татарстанда өйдә укучы балалар саны биш тапкыр арткан

> 15

ЧИТТӘН КАРАШ

Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге рәисе, Тукай бүләге иясе Факил Сафин белән әңгәмә

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 131 (28904) | Җомга | 9 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

pixabay.com

ИРКЕНӘЮ БӘҺАСЕ

ТАТАРСТАНГА КОРОНАВИРУСНЫҢ ЯҢА ДУЛКЫНЫ КИЛДЕ

Саулыкның кеше өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуын кабат искә төшерер чак җитте бугай. Азга гына онытылып торган, әмма һич кенә дә югалмаган, кешелек белән хушлашырга ашыкмаган коронавирус кабат якаларга ябыша башлады. Чирләүчеләрнең кайсылары авыруны бик җиңел кичерә, тик кемнәргәдер хастаханәдә озаклап ятып чыгарга туры килә. Чирләгән очракта нишләргә? Ничек сакланырга? Вазгыятькә бәя биреп, белгечләр белән шушы сорауларга җавап эзләдек.

> 6–7

Ишетми калмагыз

Казанда 21–23 сентябрьдә узасы Фиджитал уеннарга йөзләп киберспортчы килер дип көтелә. Әлеге ярыш Татарстан башкаласында 2024 елның февралендә буласы «Киләчәк уеннары»на әзерлек ниятеннән оештырыла.
«Дөресен әйтик: бу әле – безнең өчен дә яңалык. Бу – киләчәккә бер адым да. Барлык инновацияләрне кулланып карарга һәм безгә ярышларны да шәп итеп оештырырга кирәк», – диде журналистлар белән очрашуда Татарстанның спорт министры Владимир Леонов.
Фиджитал уеннар дүрт төрле юнәлеш буенча узачак. Болар – фиджитал футбол, фиджитал баскетбол, виртуаль чынбарлык уены, дроннар ярышы.
Искәртеп үтик: Фиджитал уеннар чынбарлык һәм цифрлаштыруны берләштерә, спортчылардан техник, цифрлы, физик әзерлек таләп итә. Катнашучы цифрлы дөньяда да, чынбарлыкта да футбол уйный.

Татарстан эшмәкәрләре ташламалы яңа программа буенча кредит (барлыгы 3,1 миллиард сум) алу өчен 26 заявка тапшырган. Акча урта бизнес өчен – 3, кече бизнес һәм микробизнес өчен 4,5 процентлы ставка белән бирелә. Бер атна эчендә генә дә эшмәкәрләр 250 миллион сумнан артыграк кредит алган.
Икътисад министрлыгыннан хәбәр ителгәнчә, эшкәртү производствосы, кунакханә бизнесы, транспорт һәм логистика оешмалары 1 миллиард сумга кадәр кредит алу мөмкинлегенә ия. Акчаны алар инвестицион максатка – әйтик, яңа производство оештыру өчен бина, бүлмә сатып алуга яки җитештерү бинасы төзүгә тота ала. Дәүләт ярдәме эшмәкәрләргә, җиһазларны тизрәк сатып алып, продукция җитештерә башлау мөмкинлеге бирәчәк.

Эт-мәчеләрне урамда ташлап калдыручыларга 30 мең сумга кадәр штраф яный. Дәүләт Думасының Экология һәм әйләнә-тирә мохитне саклау комитеты рәисе беренче урынбасары Владимир Буратов белдергәнчә, Россиядә хайваннарга карата рәхимсез мөнәсәбәт өчен яңа штрафлар кертелә.
Ә инде эт-мазар кемнедер тешләсә, хуҗасы тагын да зуррак штрафка тартылырга мөмкин. Бу очракта штраф күләменең 200 мең сумга җитүе ихтимал.

Татарстанда атна ахырына кадәр бик суык һава көтелә. Киләсе атна башында гына бераз җылыта. Гидрометеоүзәк фаразына караганда, шимбә – 10 сентябрьдә Татарстанның көнчыгыш районнарында яңгыр явачак. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +9...+14 градус, төнге сәгатьләрдә +1...+6 градус күрсәтәчәк. Уйсу урыннарда туфракка кырау төшәргә мөмкин. Якшәмбе – 11 сентябрьдә аяз булачак, явым-төшем көтелми. Көндез +11...+16, төнлә +2...+7 градус. Урыны белән кырау төшүе бар.
Синоптикларның башлангыч мәгълүматларына караганда, киләсе атна башында – 12–13 сентябрьдә күк йөзе аяз булачак. Көндез бераз җылыта: +15...+18 градус. Төнлә +2...+7. Белгечләр аңлатуынча, көннәрнең бик салкын торуы (нормадан 4–6 градуска түбән) көчле циклон үтеп керүгә бәйле.

Районнарда ни хәлләр?

Алабуга

Район башлыгы урынбасары Олег Колпаков шәһәр һәм район тормышына багышланган киңәшмәдә ике укытучыга «Лада Гранта» автомобиле ачкычларын тапшырды. «Мобиль укытучы» проекты кысасында Олы Шүрнәк урта мәктәбенең тормыш иминлеге нигезләре һәм физкультура укытучысы Илгиз Сәлимов һәм инглиз теле укытучысы Рәмзия Сәлимова эшкә машинада йөреячәк. Укытучылар Мамадышта яши һәм менә инде өченче ел рәттән Алабуга районына килеп, балаларга белем бирә.
(«Алабуга нуры»)

Азнакай

Шәһәрнең «Тарсус» паркында татар иҗтимагый тормышында һәм аның мәдәнияте тарихында зур роль уйнаган шәхесләр хакында мәгълүмат такталары куелды. Әлеге такталарда татар һәм рус телендә Габдулла Тукай, Каюм Насыйри, Кол Шәриф, Кол Гали, Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхретдин, Гаяз Исхакый, Фәрит Яруллин, Салих Сәйдәшев, Хәсән Туфан, Муса Җәлил, Галиәсгар Камал һәм якташларыбыз Әзһәр Шакиров, Нәҗибә Ихсанова кебек шәхесләр турында язылган.
(«Азнакай»)

Арча

17 сентябрьдә районда «Ат көне» үтәчәк. Ул 2015 елдан бирле ел саен уздырыла. Ат спорты фестивале кысасында ат чабышлары, милли конкурслар көтелә. Бу көнне 120, 100, 80 һәм 40 км арага ат чабышы буенча иң зур халыкара ярышларның берсе – «Халыкара БДБ кубогы» узачак. Республикада беренче мәртәбә 160 км дистанциягә чабышлар буенча Россия Кубогын уздырырга җыеналар. Чабышларда Карачай-Черкес, Кабарда-Балкар, Төмән, Пенза, Липецк, Оренбург, Мәскәү өлкәләреннән, Самара, Саратов, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән спортчылар катнашачак.
(Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәте)

Баулы

Район башкарма комитетының ЗАГС бүлегендә Алинә һәм Радик Таҗетдиновлар гаиләсен котладылар. Аларның гаиләсендә өч игезәк бала дөньяга килгән. Сабыйларга Камилла, Әминә һәм Ралина дип исем кушканнар. ЗАГС бүлеге җитәкчесе Сирена Мөрсәлимова гаилә башлыгына туу турында таныклыклар, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның котлавын тапшырды. Район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илмира Хөснуллина яңа туган сабыйларга бүләкләр тапшырды.
(«Баулы-информ»)

АКЧАНЫҢ УРЫНЫ БИЛГЕЛЕ

Дөньякүләм билгесезлек яңа таләпләр куя. Татарстанның 2023–2025 елларда икътисади үсешен, киләсе елга республика бюджетын фаразлауга багышланган утырышта Премьер-министр Алексей Песошин шулай дип белдерде. Президент Рөстәм Миңнеханов утырышта видеоконференция элемтәсе аша катнашты.

Алексей Песошин белдерүенчә, Татарстанның 2023–2025 елларда икътисади үсешенә фаразлар республика икътисадының агымдагы күрсәткечләре, әйдәп баручы оешма, министрлык һәм ведомство мәгълүматлары нигезендә төзелгән. «Дөнья һәм ил күләмендә үсеш юлын билгеләүдә билгесезлек саклана. Безнең илгә ясалган моңарчы күрелмәгән басым нәтиҗәсендә яңа таләпләр пәйда булды», – диде Премьер-министр.

Хөкүмәт Рәисе китергән мәгълүматларга караганда, быелның гыйнвар – июль аралыгында республикада тулай төбәк продукты 2 триллион 116 миллиард сум тәшкил иткән. Бу узган елның шул ук чоры дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә – 105,6 процент.

Вазгыятьнең катлаулы булуына карамастан, төбәкнең тулай продукты, сәнәгатьтә җитештерү темплары, төзелеш күләмнәре – барысы да әйбәт. «Җиңел булмаса да, әлеге тенденцияне сакларга кирәк», – диде Татарстан Президенты. Аның әйтүенчә, бүген логистика, товар, чимал белән тәэмин итү өлкәсендә зур кыенлыклар хөкем сөрә. Безгә яңа базарлар табарга, барлык юнәлешләр буенча эшләргә киләчәккә билгеләп үтте ул. «Бүген төп бурыч – республика икътисады эшен тәэмин итү. Ә бу – предприятие, оешмалар, зур һәм кече бизнес, сәнәгать, – диде Татарстан Президенты. – Фаразлардагы күрсәткечләрне тормышка ашырырга тиешбез».

Рөстәм Миңнеханов җитештерүчеләр белән аерым эшләргә чакырды. «Тармак министрлыклары һәм муниципалитетлар һәр җитештерүче белән аерым эшләргә, производство программаларын тормышка ашырырга ярдәм итәргә тиеш. Киләчәгебез предприятиеләребезнең тотрыклы һәм уңышлы эшләвенә бәйле, бары үз көчебезгә генә исәп тота алабыз», – диде Президент.

САН

Татарстан финанс министры Радик Гайзатуллин китергән саннарга караганда, республиканың 2023 елга тупланма бюджетында салым һәм салым булмаган керемнәрнең гомуми күләме – 342,5 миллиард сум, 2024 елга – 366,3 миллиард сум, 2025 елга 390,9 миллиард сум күләмендә фаразлана.

Ул, 2023 елга бюджетны формалаштыру һәм социаль-икътисади үсеш фаразларына кагылып, инвестицияләрнең гомуми күләменең сакланып калачагын искәртте. Шул ук вакытта Рөстәм Миңнеханов дефицитлы бюджет кабул итү планлаштырылуын әйтте. «Без мәктәпләр, балалар бакчалары төзергә, хастаханәләрне төзекләндерергә, яңа юллар салырга телибез. Болар барысы да агымдагы елны бердәм тырыш хезмәт белән төгәлләүгә һәм киләсе елга куелган бурычларга бәйле булачак», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов Министрлар Кабинеты утырышында катнашучылар игътибарын республикада салым бурычының 3,5 миллиард сумга артуына юнәлтте. Хәзерге вакытта аның гомуми күләме 12,5 миллиард сум тәшкил итә. Татарстан Президенты салым бурычына бәйле вазгыятьне ачыкларга кушты. «Иң мөһим бурыч – салым әҗәте үсүгә юл куймау», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Казанда яңа хәрби госпиталь ачылды. 150 урынга исәпләнгән медицина үзәге Рауис Гәрәев урамында – РКБ һәм ДРКБ янәшәсендә урнашкан.

Бер ел эчендә төзелгән госпитальне ачу тантанасында Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин һәм Россия Кораллы Көчләре Генераль штабы җитәкчесе – Россия оборона министрының беренче урынбасары, армия генералы Валерий Герасимов катнашты. Алексей Песошин Россия оборона министры Сергей Шойгуга Татарстан башкаласында госпиталь төзелеше турында карар кабул итүдә ярдәм иткәннәре өчен рәхмәт белдерде. «Хәрби медицина тарихы дәвам итә. Яңа хәрби госпиталь – заманча барлык таләпләргә җавап бирердәй күппрофильле медицина оешмасы», – диде ул. Валерий Герасимов билгеләп үткәнчә, Оборона министрлыгы сәламәтлек саклау системасын ныгытуны аерым контрольдә тота. Аның әйтүенчә, узган елның 9 аенда гына да министрлыкның хәрби-төзелеш комплексы көче белән Россиянең 27 төбәгендә 30 дәвалау үзәге ачылган.

Госпитальнең диагностика комплексында 120 ятак урынга исәпләнгән көндезге стационар, клиник диагностика лабораториясе, шулай ук кабул итү, стоматология, нурланыш диагностикасы, физиотерапия бүлекләре булдырылган. Дәвалау корпусында исә операцияләр ясау, хирургия, терапия, неврология, тән тиресе авырулары бүлекләре, шулай ук бер сменага 250 кешене кабул итү мөмкинлеге бирердәй поликлиника урнаштырылган. Медицина үзәгенең 30 урынга исәпләнгән йогышлы авырулар корпусы да бар. Госпиталь аварияләр, һәлакәтләр һәм локаль хәрби конфликтларда зыян күрүчеләргә ашыгыч махсус медицина ярдәме күрсәтү мөмкинлеген исәпкә алып төзелгән.

Ике районда – яңа җитәкче

Татарстанның ике районында җитәкчелек алмашынды. Элеккеге башлыкларның яңа эш урыннары да билгеле. Илдар Таҗетдинов Балык Бистәсеннән – «Алабуга» махсус икътисади зонасына, Фердинат Дәүләтшин Чирмешәннән Казанга күчә.

Чәршәмбе көнне Балык Бистәсе районы Советы хакимият башлыгы Илдар Таҗетдиновның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар чыгарды. Ул үз теләге белән отставкага китте. 45 яшьлек Илдар Таҗетдинов район белән 2018 елдан бирле идарә итте. Хәзер исә «Алабуга» махсус икътисади зонасында генераль директор урынбасары булачак. Сүз уңаеннан, Балык Бистәсенә кадәр дә ул махсус икътисади зонада хезмәт куйган иде. Татарстан Президенты Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров Илдар Таҗетдиновның район хакимияте башлыгы вазыйфасындагы эшен уңай бәяләде һәм аңа «Фидакарь хезмәт өчен» медален тапшырды. Татарстан Икътисад министрлыгының социаль-икътисади күрсәткечләр буенча соңгы рейтингында Балык Бистәсе районы 29 нчы урынны били.

Моннан ары район башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкару 42 яшьлек Радик Исламовка йөкләнде. Моңа кадәр ул Чистай шәһәрендә «Квест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры вазыйфасында эшләгән. Әсгать Сәфәров билгеләп үткәнчә, Радик Исламов хуҗалык эшендә зур тәҗрибәгә ия. Үзен җаваплы, иҗтимагый яктан актив җитәкче буларак таныткан. Өч чакырылышта Чистай шәһәр Советы депутаты булып эшләгән.

Чирмешән районы белән 2014 елдан бирле җитәкчелек иткән Фердинат Дәүләтшин да вазыйфасыннан үз теләге белән китте. Нәтиҗәдә район Советы аның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар чыгарды. 62 яшьлек Фердинат Дәүләтшин алга таба Казанда – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясендә эшләячәк. Район Советы утырышында катнашкан Әсгать Сәфәров аның хакимият башлыгы вазыйфасындагы эшен югары бәяләде һәм «Дуслык» ордены белән бүләкләде. Социаль-икътисади рейтингта Чирмешән районы 18 нче урынны били.

Район Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын алга таба Рамил Айбәтов башкарачак. Аны районда яхшы беләләр. Рамил Айбәтов Бәркәтә-Ключи авылында туган. Казан авыл хуҗалыгы институтында белем алганнан соң, 9 елдан артыграк туып-үскән районының авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә эшләгән. Соңгы елларда Чирмешән автотранспорт предприятиесендә җитәкчелек эшендә булган.

КАЗАННЫҢ КИНОЛЫ КӨННӘРЕ

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНА ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘН 130ЛАП КИНЕМОТОГРАФИСТ КИЛДЕ

Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең матбугат үзәге

Бу көннәрдә Татарстан башкаласы кино йогынтысында яши. Казанда унсигезенче тапкыр халыкара мөселман киносы фестивале уза. Фестивальне, елдагыча, кызыл келәмнәр җәеп, кунакларны чәкчәкләр белән каршы алып ачып җибәрделәр. Казан Ратушасында узган тантаналы ачылышта без дә булып кайттык.

Гадәттә, фестиваль кунаклары уза торган кызыл келәм тирәсе халык белән тула иде. Быел, әллә көне суык булганга, әллә тантаналы ачылыш вакытында «Ибн-Фадлан» фильмын күрсәткәнгә, тамашачылар сафы сирәгрәк күренде.

Кунаклар үзләре моңа бик борчылмады, ахры. Казахстаннан килгән Алмагөл Тлеуханова каршы алучы якның кунакчыллыгын мактап туя алмады. Фестиваль ачылышына милли киемнәреннән килгән ханым – Татарстан һәм Казахстанның уртак кинопроекты, Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар» әсәренә нигезләнеп төшерелгән «Тарлан» фильмының продюсеры. Сүз уңаеннан, ул фильм фестивальнең төп конкурс программасына да кертелгән. Өстәвенә, аңа ике як та зур өметләр баглый. Без «Тарлан»ның продюсеры белән җәһәт кенә шул турыда сөйләшеп алдык.

– Әлеге проектны тормышка ашыру идеясе дә нәкъ менә мөселман кинофестивалендә барлыкка килде. Аны төшерү – үзе бер тарих. Безгә пандемия комачаулады. Чикләрне ябып куйгач, төшерү төркеменә, шул исәптән, режиссер Юлия Захаровага да Казахстан белән чикне җәяүләп узарга туры килде. Авырлыкларга карамастан, фильм әзер, һәм без аны быелгы фестивальдә тәкъдим итәчәкбез. Алай гына да түгел, «Тарлан» төп конкурс программасына кертелде. Безнең уртак проектыбыз жюри тарафыннан да югары бәяләнеп, җиңү яулар дип өметләнәм, – диде Алмагөл Тлеуханова.

Гомумән алганда, быел фестивальгә дөньяның 44 иленнән 625 гариза килгән. Мондый зур сан фестивальнең дәрәҗәсе турында сөйли. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ачылыш тантанасында әнә шулай диде.

– Быел Казан халыкара мөселман киносы фестивале Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы кысасында, аеруча тантаналы мохиттә уза. Әлеге чара елдан-ел тамашачы мәхәббәтен ныграк яулый. Без ел саен дөньяның төрле илләреннән кунаклар кабул итәбез. Фестивальнең кирәклеген аның географиясенең елдан-ел киңәюе дә раслый. Быел 44 илдән 625 гариза килгән. Нинди зур сан! Фестивальдән чын бәйрәм ясаганнары өчен оештыручыларга зур рәхмәт! – диде ул.

Әлеге фестиваль 2005 елдан бирле, ягъни унсигезенче тапкыр уздырыла. Монысы да аның әһәмиятен чагылдыра. Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил Гайнетдин сәламләү хатында шулай дип белдергән. Кунакларны аның исеменнән Рушан хәзрәт Аббясов котлады.

– Әлеге кинофестивальнең мөһим миссиясе – диалог. Монда төрле мәдәниятләр, гореф-гадәтләр кисешә. Иң мөһиме – рухи әхлак алга сөрелә. Кино, сәнгать аша кешелек өчен мөһим булган рухи-әхлакый кыйммәтләрне тарату гаять әһәмтятле, – диелгән хатта.

Фестивальнең жюри рәисе, Россиянең халык артисты Владимир Хотиненко исә әлеге чараны күпмилләтле мәдәниятнең матур һәм якты күренеше дип атады.

Фестивальдә жюри әгъзаларына җамгысы 13 номинация җиңүчеләрен ачыкларга туры киләчәк. Алар: «Иң яхшы милли фильм» (җиңүчегә – 200 мең сум), «Иң яхшы документаль милли фильм» (100 мең сум), «Иң яхшы кыска метражлы милли фильм» (100 мең сум), «Балалар өчен иң яхшы милли фильм» (100 мең сум). «Иң яхшы тулы метражлы уен фильмы» исемен яулаучыга Гран-при бирелә. Моннан тыш, «Тулы метражлы иң яхшы фильм режиссеры», «Иң яхшы тулы метражлы уен фильмы сценарие», «Тулы метражлы фильмда иң яхшы оператор эше», «Тулы метражлы уен фильмындагы иң яхшы ир-ат роле», «Тулы метражлы уен фильмындагы иң яхшы хатын-кыз роле», «Кыска метражлы иң яхшы уен фильмы», «Тулы метражлы иң яхшы документаль фильм» номинацияләрендә җиңүчеләр ачыкланачак. Ел саен фестивальнең жюри әгъзалары Татарстан Президентының «Кино сәнгатендә гуманизм өчен» дигән махсус бүләге иясен дә сайлый. Җиңүчегә 500 мең сум күләмендә акчалата премия вәгъдә итәләр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Уңышлы хезмәттәшлек

Казанда Казахстан мәдәнияте көннәре уза. Кунаклар арасында Казахстанның Россиядәге Гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе Ермек Кошербаев та бар. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән очрашуда төбәкләр арасындагы элемтәләр һәм парламентара хезмәттәшлекне киңәйтү мөмкинлекләре турында сөйләштеләр.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Казахстан белән Татарстан арасында нык икътисади һәм мәдәни элемтәләр урнашты. «Татарстанда Казахстан мәдәнияте көннәре бик уңышлы уза. Кичә 18 нче Халыкара мөселман киносы фестивален ачтык. Аның кысасында Казахстанның биш фильмы күрсәтеләчәк. Бу атна ахырында Татарстан Президенты кушуы буенча Казахстанның Абай өлкәсендә Халыкара Иртыш буе Сабан туенда катнашырга җыенам. Татарлар күп яши торган шәһәрдә – Сәмәйдә дә татар сәнгать мәктәбенә 30 ел тулуга багышланган чаралар узачак», – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Ермек Кошербаев барлык өлкәләрдә үзара файдалы хезмәттәшлекне дәвам иттерүгә ышаныч белдерде. «Казахстан белән Татарстан арасында икътисади хезмәттәшлек уңышлы үсә, – дип билгеләп үтте ул. – Казахстанда уртак проектлар гамәлгә ашырыла, яңа эш урыннары булдырыла. Иң мөһиме – җыю предприятиеләре генә түгел, ә тулы кыйммәтле предприятиеләр бу. Нефть-газ тармагында, шин җитештерү һәм сәнәгатьнең башка өлкәләрендә бик мөһим проектларга кул куелды. Мәдәни һәм гуманитар проектларны тормышка ашыру сөендерә. Шуларның берсе – Казахстанның күп кенә төбәкләрендә Сабан туе бәйрәме узды».

Рәсми хәбәрләр

Казанда, Россия Юстиция министрлыгы оештырылуга 220 ел тулуга багышлап, министрлыкның Татарстан буенча идарәсенең тантаналы җыелышы узды. Бәйрәм уңаеннан идарә коллективын һәм ветераннарын республика җитәкчелеге исеменнән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

Фәрит Мөхәммәтшин үзенең чыгышында Казан губерниясенең Сокуры авылында туып-үскән күренекле дәүләт эшлеклесе, атаклы шагыйрь Гавриил Державинның Россиядә тәүге юстиция министры булганлыгын искә төшерде. «Ике йөз елдан артыграк вакыт дәвамында әлеге мөһим дәүләт институты илнең бердәм хокукый кырын ныгыту, законлылыкны, хокук тәртибен саклау бурычларын үтәп килә, – диде ул. – Татарстан идарәсе, өлкән буыннар салган данлыклы традицияләрне саклап һәм ишәйтеп, күп еллар дәвамында үзенең хезмәт бурычын тел-теш тидергесез үтәп килә. Идарәнең Татарстан Юстиция министрлыгы, һәм, әлбәттә инде, республика Дәүләт Советы белән нәтиҗәле рәвештә бергәләп эшләве бик мөһим».

Фәрит Мөхәммәтшин, җәмгыятьтә юридик хезмәтләргә ихтыяҗның зур булуын искәртеп, август азагында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Россия юстиция министры Константин Чуйченко катнашында ачылган «Юстиция кварталы»н югары бәяләде. «Барлык хокукый хезмәтләрне бергә туплаган заманча урын бу. Бигрәк тә яшь белгечләр – студент юристлар да һөнәргә өйрәнәчәк, – диде республика парламенты башлыгы. – Татарстанда яшәүчеләрнең биредә юридик консультацияләрне сыйфатлы һәм тулы күләмдә алачагына ышанам».

Фәрит Мөхәммәтшин идарә ветераннарына аерым рәхмәт сүзләре җиткерде.

Салих Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концертлар залында Финанс хезмәткәрләре көненә багышланган тантаналы чара узды. Финанс өлкәсе хезмәткәрләрен һәм ветераннарын һөнәри бәйрәмнәре уңаеннан республика җитәкчелеге исеменнән Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

Дәүләт Советы Рәисе парламент һәм финанс органнары, Финанс министрлыгының законнар иҗат итү эшчәнлегендәге зур хезмәтен билгеләп үтте. «Парламент комитетлары һәм алар каршындагы Экспертлар советлары белән тыгыз хезмәттәшлек җайга салынды. Бюджет чыгымнарын таләп итүче бер генә закон проекты да сезнең игътибардан читтә калмый, – диде ул. – Ел саен республиканың төп финанс документын кабул иткәндә һәм үтәгәндә бик зур уртак эш башкарыла. Аның һәр этабында – бюджет проектын Дәүләт Советына кертүдән, парламент тыңлаулары процедурасыннан алып тавыш биргәнче – сезнең кызыксынуны һәм җаваплылыкны тоябыз».

Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, республика Финанс министрлыгының тотрыклы һәм төгәл эше профессионаллар командасына һәм аның башлыгы – ведомствоны 20 ел дәвамында җитәкләүче Радик Гайзатуллинга бәйле. «Татарстанның финанс системасында үз эшенең чын мәгънәсендә осталары, югары квалификацияле белгечләр эшләвен канәгатьлек хисе белән билгеләп үтәсем килә», – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Әйтеп кенә бактым

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Курку

Соңгы вакытларда лаеклы ялга чыккан ирләрнең – хатыннарыннан, хатыннарның ирләреннән зарлануын ишетергә туры килә. 30–40 ел пар күгәрчендәй яшәгән бәхетле парлар ни өчен бәхетсезгә әйләнә башлады соң, алар ни өчен бер-берсеннән туйган? Бу – гайре табигый хәл. Бөтен авырлыкларны бергә кичергән, шатлык-кайгыларны уртак итеп күпме гомер яшәгән парлар инде бербөтенгә әйләнергә тиеш иде кебек.

Менә бер атна буе әлеге хәлнең сәбәбе турында уйланып йөрим, хатыннан берәр катырак сүз ишетсәм, күңелгә шик керә. Җитмәсә, телефон аша танышлар да зарлангалый башлады. Берсенең хатыны беркөнне: «Ир кешенең иртән эшкә чыгып киткәне яхшы», – дип ычкындырган. Танышым, еларга җитеп, миңа телефоннан шалтырата. «Хатынкызга җитмәсә җитми икән, малай. Инде эшли-эшли җитмешне тутырып килә, авыртмаган җир юк. Бераз зарлана башласам, хатын: «Әнә фәлән кешенең ире почти инвалид, эш калдырганы юк бит әле», – дип кенә куя. Нишләргә инде?» – ди. «Эшләргә инде», – дип шаяртам шаяртуын, әмма мондый көн миңа да килеп җитәргә мөмкин бит.

Хәер, миңа өйдә мөнәсәбәт башка, хәзергә дип әйтик. «Арысаң, тукта!» – дип кенә торалар. Уйлап, борчылып, шатланып арысам, кеше арасына чыгудан туктап, өй тавыгына әйләнсәм, мин нинди журналист-язучы булам инде? Мине иң әүвәл әнә шунысы куркыта. Гел өйдә утырган кеше артык ваклана, кирәкмәгәнне дә күрә башлый бит ул. Пенсиягә китү – «меҗ-меҗ карт» яшенә җитү.

Менә исәпләп утырам әле: ир белән хатын 30 ел яшәсәләр, ничә ел «агылый белән тагылый» кебек бергә булганнар икән? Мөгаен, 15 ел чамасы гынадыр, бәлки, аннан да аздыр. Чөнки атнаның биш көнендә алар бер-берсен иртә-кич кенә күрә. Чөнки икесе дә көн буе эштә. Шимбә-якшәмбе көннәрендә дә җитәкләшеп кенә йөрмиләрдер. Менә шуларны исәпкә алсаң, 30 ел бергә яшәү дигәннәре 7–10 елга гына калмый микән әле. Ә инде икәүләшеп пенсиягә чыккач, «бәхетле» парлар өчен бөтенләй икенче төрле тормыш башлана: ир белән хатын бер-берсеннән гаеп эзли башлый. Хәтта берәрсенең авыз чапылдатып ашавы да ошамый. Ә бит әле кайчан гына алар бер-берсенең авызларына гына карап торалар, иреннәр исә дөнья йөзләрендә иң татлы нәрсә кебек тоела иде. Берәрсенең хихылдап я шаркылдап көлүе сандугач сайравы кебек кабул ителә иде. Ә хәзер... Бер танышым үзенең ире турында: «Атлап йөрүләренә хәтле җенем сөйми», – дигән иде. Бу сүзләрне гомергә онытасым юк. Онытыр идем: «Нәрсә картлар кебек бөкрәеп йөрисең, туры гына атлап булмый мәллә?» – дип әйткәләп торалар. Да, куркыта картлык дигәннәре. Озак еллар бергә яшәүче бәхетле парларны мин гомер буе бер-берсенә таба атлаучылар дип күзаллыйм. Алар мәңгелек мәхәббәт сукмагыннан атлыйлар кебек. Ә «мәхәббәт» дигән олы хисне югалтучылар бер-берсенә таба түгел, ә яшәш, параллель сукмаклардан атлыйлардыр кебек. Параллель сызыклар, белгәнебезчә, беркайчан да кушылмый.

Менә шундый уйларга бирелеп утырганда, хатынымның тавышы ишетелде: «Эшкә соңга калмыйсыңмы?»

Ярый әле: «Ир кешенең һәркөнне иртән эшкә чыгып киткәне яхшы», – дип өстәмәде.

«Соңга калмыйм, хәзер кузгалам», – дидем дә: «Синнән аерыласы килми, шуңа күрә генә бераз соңардым», – дип өстәгән булдым.

Миңа хатынны гел янәшәмдә тою чыннан да рәхәт. Эштән дә сагынып кайткан булам бит әле шул хәсрәтне. Әни әйтмешли, «вәт дивана». Мәхәббәттән дивана булуга ни җитә диген, име!

Өйдә савыт-саба шалтырамый тормый инде ул, монысы – хак. Күптән түгел кавышуыбызга 50 ел тулды, әмма, бик сирәк булса да, сүзгә килеп алгалыйбыз. Мин монысында да мәхәббәтне «гаеплим», ул хисне югалткан булсак, гомумән, авыз ачып, сүз дә әйтәсе килмәс иде, алай гына да түгел, бер-беребезне күрмәмешкә салышыр идек, дип уйлыйм. «ВТ»ның бу санын хатынга күрсәтмәм, «алтын туй» турында шаулап йөрмәскә дип килешкән идек. Чөнки күз тиюдән куркабыз. Бу язма очраклы рәвештә аның кулына кереп, тавыш-мазар чыкмаса ярый инде. Менә шулай курка-курка яратып яшәп ятыш.

КОРАЛ ЯРЫШЫ

Дөньякүләм конфликтлар арткан һәм кискенләшкән заманда яшибез. Рим папасы Франциск, 1 сентябрьдә Беренче Бөтендөнья сугышы башланган датаны билгеләп үткәндә, Өченче Бөтендөнья сугышының инде баруын әйтте. Папа белән килешергә була, килешмәсәң дә ярый, әмма хәл, чынлап та, катлаулы.

Моңарчы үзен нейтраль дип санаган дәүләтләр дә бүген ашкынып коралланырга керешә. Аларның элек үзләрен пацифистлар дип санаган халыклары да хәзер лидерларын коралланырга өнди. Иң күп тиражлы япон газетасы «Иомиури» үткәргән сораштыруның нәтиҗәләре менә мондый: халыкның 70 проценты илнең хәрби потенциалын арттыру яклы. Хәтта оппозиция тарафдарларының да 68 проценты хәрби бюджетны үстерү ягында. Японнарның 81 проценты төп дошманнары дип кытайларны атый икән. Югыйсә алар бүген, НАТО блогы кебек үк, эчке тулай продуктларының 2 процентын хәрби максатларга тотарга ниятли. Япон эчке тулай продуктының дөньяда иң зурлардан булуын аңлау оборона бюджетының нинди булачагын күзалларга ярдәм итә. Югары технологияле кораллар җитештерү японнар өчен бик җиңел. Әле күптән түгел генә Көнчыгыш Кытай диңгезендә хәрби өйрәнүләр вакытында аталы HIMARSлар («Хаймарс») артыннан «Тип 12» япон реактив залп бирү системалары атты. «Тип 12»ләрне дөнья җәмәгатьчелеге бик белми. Алар «Хаймарс»ларга охшаган, әмма Америка системаларының максималь ату ераклыгы 300 километр гына булса, япон РСЗОларын мең километр ераклыкка ата торган ракеталар белән коралландырырга уйлыйлар. Мең километрга һәм тегү итеп ата торган «Катюша»ны күз алдына китерегез әле. Япон хәрби бюджеты снарядлар һәм ракеталар җитештерү өчен күп акча тотарга ниятли, чөнки сугыш башлана калса, снарядлары ике ай атарга гына җитә икән.

Нинди генә кораллар юк хәзерге дәүләтләр кулында. Сер түгел: Россиянең көнбатышындагы махсус хәрби операциянең озакка сузылуы Төньяк Атлантик блок илләренең Киевны яңа технологик кораллар белән даими тәэмин итеп торуына да бәйле. Соңгы көннәрдә генә немецлар (байтагы әле дә Россиягә симпатия белдерүче халык) Украинага COBRA дип аталган радиолокацион системаны китерде. Бу система күз ачып йомганчы дошман артиллериясенең кайдан атуын ачыклый һәм шулай ук Германиядән китерелгән GEPARD зениткалары эшкә керешә. Артиллеристларга качып котылу мөмкинлеге калмый диярлек. Россиядә дә бар андый системалар, билгеле. Менә шуннан хәзерге сугышны күз алдына китерә аласызмы?

Элек хәлсез генә булып саналган һәм артта калган дип исәпләнгән дәүләтләр яңа технологияләр белән сугыш мәйданына чыга. Карабах сугышыннан соң төрек беспилотникларының дәрәҗәсе бик артты. Төрекләрнең ул чакта яңа сугыш сценарием тормышка ашыруларын Вашингтонда да билгеләп үттеләр. Дистәләгән ил бүген мәшһүр «Байрактар»ларны үзенә сатып алырга тели. Румыния, мәсәлән, Израиль беспилотникларын алуны туктатып, «Байрактар»ларга күчте. Искиткеч беспилотник булып саналса да, идеаль үк түгел инде алар түгеллеккә. Россия РЭБлары, әйтик, Украинада аларның байтагын җиргә төшеп утырырга мәҗбүр итте. Нишләтәсең, электрон системалар радиосигналлар тукталуга бик сизгер шул. Әмма, мәтәлгәнче, төрек «кош»лары үзләре дә бик зур зыян сала. Аннан соң алар арзанлы санала. Өченчедән, һөҗүм итүчеләр арасында үлүче юк, яраланучы юк. Оператор үз эшен башка дрон белән тоткарлыксыз дәвам итә ала.

Baykar Technology компаниясе якындагы айларда беспилотниклар җитештерүне кискен арттырырга җыена. Берничә ел эчендә хәзерге көнгә 400 Bayraktar TB2 һәм 20 Bayraktar AKINCI җитештерелгән инде. Соңгысының, AKINCIның сугыш кырында үзен күрсәткәне юк әле. Ләкин, бәхәссез, ул – тагын да дәһшәтлерәк корал. Төрекләр җитештерүне арттырырга ниятли. 2022 елда җитештерелгән беспилотникларның 98 проценты экспортка китә. Нигездә бер илгә озатыла. Кайсы ил икәнен әйтеп тормыйбыз, үзегез чамаларсыз.

Компаниянең генераль директоры Халук Байрактар сан артыннан гына кумый, сыйфат ягын аеруча кайгырта. Соңгы атналарда гына аларның Гебзәдәге

мультимедиа.минобороны.рф

техник университеты һәм Fly BVLOS Technology компаниясе Тайвань галимнәре белән килешү төзеделәр. Тайвань һәм төрек белгечләре двигательләр, чиплар һәм батареялар юнәлешендә фәнни тикшеренүләр алып барырга җыена. Тайваньлылар җыйган нечкә чипларны бер илдә дә җыя алмыйлар. Төрек беспилотникларын тагын да дәһшәтлерәк итәргә ниятлиләр.

Аларның бүгенге перспектив модельләре үк инде күңелдә шом тудыра. Польшада яңа гына MSPO 2022 сугыш кораллары күргәзмәсе ачылды. Анда 26 төрек компаниясе катнаша һәм алар оборона һәм аэрокосмик сәнәгать эшләнмәләрен күрсәтә. Төрекләрнең иң соңгы куәтле коралы – KIZILELMA беспилотнигы. Латин хәрефләрен тырышып укысагыз, «Кызыл алма» дигән сүзне танырсыз. Кызыл алманың характеристикаларын китереп тормыйбыз. Белгеч булмаганнарга нигә ул? Әмма 1500 килограмм йөк күтәрүен, гадәттән тыш яңа идарә ителешле бомбалар һәм ракеталар белән коралланувын, реактив двигательләренең тавыш тизлегенә һәм аннан да зур тизлеккә ирешерлек икәнен, стеллс-технологияләр кулланылуын, ягъни радарларга күренми торган булуын (бәреп төшерү бик катлаулы дигән сүз), 12 сәгатьтән 24 сәгатькә кадәр һавада була алуын, бик ерак очуын, үзенең радары булуын, һөҗүмнәрдән кача алу мөмкинлегенең зурлыгын әйтми кала алмыйбыз. Үзенә һөҗүм итүче ракеталарны «Кызыл алма» ачыклый һәм юк итә. Бу – дөньядагы бердәнбер шундый беспилотник. Ул җирдәге техникага гына түгел, дошман очкычларына һәм ракеталарына да һөҗүм итә ала. Төрекләр: «Авиация технологияләре өлкәсендә алга киткән илләрне куып тормыйбыз, барысыннан да алга киткән технологик беспилотниклар эшләүгә төп игътибарны бирәбез», – диләр. «Кызыл алма» күтәргән ракеталар һәм снарядларның техник характеристикаларын шулай ук сөйләмибез. Яңа двигательләре дә, ракеталары да таң калдыра торган. Иң мөһиме: боларның барысын да төрекләр үзләре җитештерә.

Әнкара һава һөҗүменә каршы торучы ераккa ата торган зенит-ракета системаларын да сафка бастырды инде. Siper дип аталган ерак радиуслы зенит-ракета комплексын яңа гына сынадылар. Уртача радиустагы Hisar-O+ һәм якын радиустагы Hisar-A+ системалары кулланылышта инде. Берничә ел элек кенә төрекләрдә андый корал юк, тулысынча АКШка бәйле иделәр.

«Baykar» галәм киңлекләренә дә чыгарга җыена. 29 августта Fergani Uzay/Fergani Sky дигән яңа предприятиегә нигез салына башлады. Предприятиегә югары басым резервуарлары инженерлары, криоген техника инженерлары һәм башка югары технологияләр өлкәсе белгечләре күп кирәк. Россиянең космик технологияләр өлкәсендә тәҗрибәсе зур булуын искә алсак, хезмәттәшлек итәргә мәйдан бар кебек. Төркиядәге Россия илчесе Алексей Ерхов төрек газетасы Yeni Şafakka интервью бирде. «Төркия Россиягә файдалы, Россия Төркиягә файдалы», – дигән фикер әйтә ул анда. Менә шул файданы тормышка ашырасы иде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ӘЛЕМ: ҮСМӘСЕН ӘРЕМ

ТУГАН АВЫЛНЫ САКЛАУ – ҺӘРКЕМНЕҢ ЭШЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Авылдагы иске клубны егерме елдан артык сүтмиләр. Бер дә матур күренеш түгел. Сынган агачлар, алабута, кычыткан, тигәнәк... – авылның ташландык хәлдә икәнлегенә бер дәлил. Иске клуб янәшәсендәге Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар өчен ачылган һәйкәл тирәсендә чәчәкләр түгел, чүп үләннәр үсә. Авылга кунакка кайтучылар да аптырап китә моңа. Кайчан иске клуб сүтелеп, тирә-ягы тәртипкә китерелер икән?»

Социаль челтәрдәге төркемебезгә Актаныш районының Иске Әлем авылыннан әнә шундый хат килде. Авторы үзенең исемен әйтмәвебезне сорады. Актаныште мондый хәл булырмы икән, дип гаҗәпләнеп, юлга кузгалдык.

Авылга утын кирәкми

Иске Әлем – 75 йортлы авыл. Ташландык йортлар да бар. 185 кеше пропискада тора, 140тан артыгы шунда яши. Быел бер генә бала да тумаган. Сабыйлардан алып техникум яшендәгеләр – 18 кеше. Аларның да күбесе –читтән килеп урнашкан яшь гаилә балалары. Монда ана капиталына йорт алучылар шактый икән. 2013 елда, бала саны аз дип, башлангыч мәктәпне япканнар. Кечкенә генә кибет бар. Клуб та эшли. Бүген авылның хәле шундыйрак.

Хәтта язылган иске клуб чыннан да тора. Күпмедер өлеше сүтелгән, тирә-ягын чүп баскан. Авылны бер дә бизәми, әлбәттә, бу күренеш. Тик иске клуб урнашкан биш йортлы урамда безне гаҗәпләндергән нәрсә ул гына түгел иде. Нибары өч йортта гына тәртип монда. Шуның да икесендә генә яшиләр икән. Берсе – 83 яшьлек Мөдәррис ага Фәрраховныкы, хатыны белән икәү генә яшиләр.

– Күршедәге йортларның хуҗалары бар анық, кызым. Тик күршеләрнең күптән күренгәне юк, кайтмыйлар, – ди, авыр сулап, Мөдәррис ага. – Клубны сүтеп, эшен бетереп куйсалар, әйбәт булыр иде. Хуҗасыз булып яткач, бер дә күңелле түгел. Янгын чыгу куркынычы да бар, Алла сакласын. Матур бакча ясасыннар иде урынында...

Матур ял урыны ясау планда бар үзе. Безне авыл буенча озатып йөргән Яңа Әлем җирлеге башлыгы Дилбәр Әнвәрованың да хыялында ул.

– 2005 елда клуб, медпунктны бер түбә астына берләштерделәр. Искесе ягылмагач таушалды. Әмма бүрәнәләре бик әйбәт әле аның. 2018 елда җирле үзидарә башлыгы булып, кире үз вазыйфама кайткач: «Әйдәгез, клубны сүтик, бу урынга балалар мәйданчыгы эшләрбез», – дип халыкка әйтеп карадым. Бүрәнәләре әйбәт бит, сүтеп алыгыз, дип тә тәкъдим иттем. Бәлкем, җитешә алмаганнардыр, ахырга кадәр сүтүче булмады, – диде ул. – 2015 елда һәйкәлне дә яңарттык. Матур бер урын ясыйсы килгән иде. Мәсьәләне хәл итү өчен узган ел «Башак» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте рәисе Илус Ярмиев янына да кердем. «Ярар, Дилбәр, сүтәрбез», – диде ул. Былтыр кар иртәрәк яткач, эш барып чыкмады. Быел да кердем. «Урак беткәч, ноябрь аенда сүтәрбез», – диде.

Аңлашыла, урак вакытында бөтен көч – басуда, барлык техника да шунда. Эшне бүлеп, ничә ел торган иске бинаны сүтәргә алынмаячаклар. «Һәр нәрсәнең – үз вакыты. Җир тундыргач, сүтәрбез», – диде җирлек башлыгы.

Актаныш районы хакимиятендә дә, Иске Әлем клуб бинасы урып-җыю эшләре тәмамлангач, хуҗалык ярдәме белән сүтеләчәк, дип вәгъдә бирделәр.

Чалгы ал да үзең чап!

Клубны авыл халкы бергә җыелышып та сүтә ала бит... Тик халыкны өмәгә чакыру җиңелләрдән түгел икән. Һәрхәлдә, Дилбәр Әнвәрова шулай диде. Сәбәбе шул: авылда яшәүчеләрнең күбесе – өлкәннәр һәм хуҗалыкта эшләүчеләр. Зиратны да күбрәк шушы авылдан киткән яшьләрне чакырып чистарталар икән. Юл буйлары, авыл тирәсендәге чүп үләннәре клуб хезмәткәрләре чаба. Быел башлык трактор чакыртып чистарттырган, әмма үлән гел үсеп тора. «Авыл бетә дип бик борчыласың икән, чалгы аласың да чыгып чабасың, аңа авыл советы кирәкми», – ди Дилбәр ханым.

– Сер түгел, авыллар бүген үзара салым акчасына көн күрә. Әмма халыктан җыелган акча беренче чиратта су һәм юл мәсьәләләрен хәл итүгә тотыла, – диделәр Актаныш районы хакимиятендә «ВТ» хәбәрчесенә. – Әлеге эшләр ел саен хисап җыелышларында авыл халкы белән килешеп башкарыла. Урамнарны чүп үләннәрдән чистарту өчен бер тиен дә каралмаган. Җирлекләр иганәчелек ярдәмендә, хуҗалык белән килешеп – кем ничек булдыра ала, шулай эшли. Җәй дәвамында һәркем үз капка төбен, үз җир кишәрлеген тәртиптә тотса, авыл урамнары, әлбәттә, чистарыр иде. Чисталык иң беренче һәркемнең үзеннән башлана.

Дилбәр Әнвәрованың бүген ташландык йортлар буенча судка документлар әзерләп йөрүе икән. Кемнеңдер баласы, кемнеңдер оныгы бар. Тик алар ул йортларны үз исеменә рәсмиләштермәгән.

– Безгә салым керми. Судка биреп, варисларны табарга җыенабыз. Йә рәсмиләштерәләр, йә урыннарны чистартып, җирләрне авыл советы җирлегенә калдырып, күпбалалы гаиләләргә йорт салырга, сораучыларга бирәчәкбез. Юл бар, яшәргә була бу авылда. Киләсе елда Иске Әлем «Вак таш салу» буенча район программасына кертелде. Хуҗалыкта эш урыны бар, акчасын түлиләр, – диде Дилбәр ханым. – Иң ачуны китергәне – мине ваемсызлыкта гаепләү. Авылда яшәүче төп халык аңлый хәлне, күбрәк читтә яшәүчеләр зарлана. Шул хатны язучыларның берәрсенең берәр тапкыр өмәгә зиратка килгәне бармы икән? Халыкның үзеннән тора, мин барысын да эшлим. Әти-әниләрем шушы хуҗалыкта эшләгәч, ике авыл өчен дә җан атам. Шушы җирнең патриоты мин!

«Суыбыз тәмле түгел»

Ямьсез клубтан башка проблемалар да бар Иске Әлемдә. Кранга үрелгән саен искә төшә торганы. Суның сыйфаты начар, дип тә зарландылар. Барып кына алырга якында гына чишмәсе дә юк. Берәүләр, судан нефть тәме килә, дип тә әйтте. Рәзифә апа Әхмәтгалиева (рәсемдә) белдергәнчә, чиләк төбенә кара булып утыра, авызга кабарлык түгел.

«Чиста су» программасына акча каралмаган, шуңа күрә җирле үзидарә башлыгы Дилбәр Әнвәровага бу мәсьәләне хәл итү өчен дә акча эзләргә туры килә.

– Бу скважинадан сасы су килә. Ферма арасында ул, бәлкем, шуңа да шулай агадыр, – диде ул, чынбарлыкны яшермичә. – Узган ел 1,5 миллион сумлык грант откан идек. Шул акчага трасса суздырдык. Алдагы елларда үзара салым акчасын җыеп, 450 метр торбасын алып калдырган идем. Быел су мичкәсен алып куябыз, аңа акча бар. Электр тоташтырырга гариза биргән идем, 2 млн 400 мең сумлык счет җибәргәннәр. Түбән Камага да, Пучыдагы электр челтәрләре оешмаларына да шалтыратып, бәясен төшереп яки бушлай эшләтеп булмыйммы, дип белештем. Чыгу юлын табарга кирәк. Үзара салым акчасы гына җитми. Аңа прожектор яктырткычын аласыңмы, кышын юлларны чистартасыңмы?

Чиста су – Иске Әлем проблемасы гына түгел. Күп авылларның баш бәласе ул. Гомумән, бернинди су булмаудан да зарланучылар шактый. Җәй айларында бигрәк тә кискен тора бу сорау. Монда да авыл халкы кемнедер гаепләү яклы түгел. «Су әйбәт булмаган өчен Дилбәр гаепле түгел бит инде, җаным», – диде 72 яшьлек Рәзифә апа.

Суның начар икәнлеге турында районда да беләләр. «Бүген әлеге вазгыятьне уңай хәл итеп, халыкны чиста су белән тәэмин итү буенча эш бара. Үзара салым акчасына чишмәдән яңа су юлы сузу һәм резервуар кую планлаштырыла. Бу эшләр быел башкарылачак», – диделәр район хакимиятендә.

Яшәргә кайтыгыз!

Авыл әле бетмәгән, үз көенә генә яшәп ята. Әремен йолкып, иске клубын сүтеп була аның. Әмма яшьләр авылда тәпләнеп калмаса, эш булмаса, юкка чыгу өчен күп кирәкми. Өлкәннәр дә авылның киләчәге өчен борчыла.

– Борчылмыйча, кая барасың? Дүрт улыбыз бар. Берсе хет төпләнеп калмасмы икән дигән идек... Яшьләр киткәч, ул да авылда калмады. Ирем белән икебезгә – ике өй, – ди әнә Рәзифә апа.

Башка йортларда да, балалар яшәргә кайтмыйлар шул, дигән сүзләрне ишеттек. Сәбәбен эш, мөмкинлекләр булмауга сылтыйлар. Дилбәр Әнвәрова исә, яшьләр кайтса, җирен дә бирәм, кайтсыннар гына, ди. «Юл, күпер салынды. Багана утлары алыштырылды, су проблемасын хәл итәрбез», – дип, Иске Әлем яшьләрен авылга яшәргә чакыра ул.

Авыл җирлеге башлыгы проблемаларның хәл итәргә тырыша. Нинди кыенлыклар белән очрашканын үзе генә беләдер. Ашаган белми, тураган белә, диләр бит. Авыл халкы үзе дә актив булсын иде. Бер йорт кына калган авыллар турында шактый язылды соңгы арада. Аларны да шундый олы йөрәкле кешеләр яшәтергә тырыша. Синең авылның синнән башка тагын кемгә кирәк? Бүген әрем, кычыткан үсәр, ә иртәгә?..

Сәрия МИФТАХОВА

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

ИРКЕНӘЮ БӘҺАСЕ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Илдар Мөхәммәтҗанов

Вазгыять нинди?

Коронавирустан авыручыларның берничә дистә, ә үлүчеләрнең бөтенләй юк булуына күнегеп, иң гади саклану кагыйдәләренә дә кул селтәгән мәлдә, чир үзенең әле дә безнең арада булуын искәртергә уйлады бугай. Россиядә чирләүчеләр – дистә мең, Татарстанда берничә йөз кеше белән исәпләнә хәзер. Күзләрдә дә язлар кабатлана, диярсең.

Төгәлрәк саннарга килгәндә, соңгы мәгълүматлар буенча, илдә коронавирусны 50618 кеше йоктырган. Тәүлек эчендә 93 кеше үлгән. 3611 кешене хастаханәгә салганнар.

Шунысы да сагайта: коронавирус инфекциясе белән авыру очракларының 12–13 проценты балаларга туры килә. Шул санның яртысыннан артыгы – 7–17 яшьлекләргә. Коронавирус яшәрә дигән сүз инде бу.

Күтелгән һәм белгечләр кисәткән чир күтәрелеше Татарстанда да күзәтелә. Соңгы тәүлектә авыручылар саны 630га җиткән. Үлүчеләр юк. 74 кешене хастаханәдә дәвалыйлар.

Хәзерге көндә республикада коронавируслы сырхаулар өчен 915 ятак әзерләгәннәр. Резервтагы буш ятаклар – 7,4 процент.

Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгы медицина оешмаларының коронавирус инфекциясе ачыкланган сырхауларга ярдәм күрсәтү өчен тиешле квалификацияле медицина персоналы, кирәк-яраклар белән тәэмин ителгәнлеге турында белдерә. Ихтыяҗ булган очракта, медицина хезмәткәрләренең резервын оештыру да мөмкин.

Чикерткә дә булыша

Татарстанда инде күптәннән үз кешегә әйләнгән Гыйрак егете Аммар Хөсәйнне газета укучылары да, Республика йогышлы авырулар клиник хастаханәсендә дәваланып чыккан кешеләр дә яхшы таныйдыр. Пандемия башланган чордан ук Аммар, Гиппократ антына тугры калып, бар көчен генә түгел, бөтен тормышын кешеләрне дәвалауга, ярдәм итүгә багышлады. Менә инде коронавируслы өченче елыбызны тутырабыз, Аммар әле дә – алгы сафларда. Медицина буенча белемен арттырырга да (6 нчы курс студенты ул), хастаханәдә эшләргә дә өлгерә, күпме татарстанлының гомерен саклап калу өчен тырыша.

– Эшебез әллә ни үзгәрмәде. Медикларның эше гел җаваплы һәм җитди. Безгә мөрәҗәгать иткән кеше – ярдәм өмет итүче инде ул, – ди табиб егет. – Авыручылар аз димәс идем. Коронавируслы сырхауларның да төрлесе килә. Кайсыларында инде чир кискенләшкән дә була. Иң куркынычы – үпкә ялкынсынуы. Әйтүемчә, эшебез – шул ук. Авырлыгы кешеләр санына бәйле. Анысы инде – чирнең дулкыннарына. Дулкын да үзебезгә – кешеләрнең аңлы булуына бәйле.

Табиб әйтүенчә, коронавирусның табигате дә гел яңарып тора.

– Яңа штаммнарны гына алыйк. Аларның санын барлап өлгереп тә булмый инде. «Омикрон» һәм «дельта» белән ешрак очрашырга туры килә, – ди Аммар. – Коронавируска бәйле вазгыять кискенләшә. Әйтүемчә, аның үз-үзен тотышы да штаммнарга бәйле. «Омикрон» үзен «дельта» кебек тотмый, йә киресенчә. Кешеләр үз сәламәтлегенә һәм якыннарына игътибарлы булсын иде.

Аммар Хөсәйн әйтүенчә, кешеләр коронавируска уңай тест күрүгә хафага төшә, борчыла башлый. Күбесе ОРВИдан да коронавирус билгеләрен эзли. Шуңа да табибларга дарудан кала, сүз белән дә ешрак дәваларга туры килә әле.

– Куркалар инде, андыйлар күп. Шундук: «Фәлән кешем коронавирустан үлде», – дип сөйли башлыйлар. Һәр минут саен диярлек: «Миндә коронавирус түгелме?» – дип сорыйлар. Мин аларны тынычландырырга тырышам. Башлангыч чордагы кебек үк куркыныч түгеллеген, дәвалауның төгәл күрсәтмәләре барлыгын әйтәм. Җиңәбез, җиңәчәкбез, дим, – ди Аммар. – Күпләр хастаханәгә ятарга да курка әле. Өйдә дәвалану белән хастаханәдәгесе бер түгел, табиблар күзәтүе астында булу яхшырак, дип аңлатырга туры килә. Хастаханәдә бит бер генә табиб тикшерми. Кардиолог та, инфекционист та, башкасы да карый. Шул очракта гына дәвалану нәтиҗәле була.

Әңгәмәдәшебезнең эш практикасында уңай вакыйгалар да булмый тормаган, билгеле. «85 һәм 97 яшьлек әбиләр реанимациядә ятты. Берсенең үпкәләре – 100, икенчесенең 60 процентка зарарланган иде. Яшьләренә карамастан, алар чирне җиңеп чыкты. Мин бу үрнәкне башкаларга да сөйлим. Дәвалау, күп очракта, сырхауның халәтенә, кәефенә дә бәйле бит ул», – дип искә алды.

Аммарның көнне төнгә ялгап эшләгән вакытлары күп булса да, зарланмый. Сырхаулар терелеп, рәхмәтле елмаеп чыгып китә икән, табиб өчен үзе бер бәхет инде бу. «Эштә кайчагында кыен була. Әмма куркыныч түгел. Безгә ярдәм итүчеләр бар. Хәтта бөҗәкләр дә! Әнә бер көнне таң белән эшләгәндә, иңемә суфый чикерткә (богомол) кунды. Шундый булышчылар да күңелне күтәрә», – дип, хезмәт урынында булган, мәшәкатьне онытырып торган бер мизгелен искә алды табиб егет.

Урап узмаган

Хезмәттәшебез – «Яңа Гасыр» каналы журналисты Михаил Любимовның да шушы арада коронавирус белән чирләп алуы билгеле булды. Дөресрәге, ул үзе бу хакта социаль челтәрләрдә хәбәр итте. Гаҗәп бит: Татарстан буенча ачылган күпчелек «кызыл зона»лардан журналист буларак сюжетлар әзерләгән кешене чир 2,5 елдан соң эзләп таба. Михаил Любимов – коронавирус турында иң күп һәм тәэсирле итеп сөйләгән тележурналистларның берсе, 80 тапкыр коронавируслы сырхауларны дәвалау өчен вакытлыча ачылган госпитальләргә хакыйкать эзләп һәм шуны башкаларга да күрсәтергә теләп кергән кыюларның сирәге.

Авыру ничегрәк узган соң? Журналист август аенда чир йоктыра.

– 2,5 елга беренче тапкыр коронавируска уңай тест тапшырдым. Дөрес, «омикрон» дулкыны алдыннан сырхау мине берничә көнгә аяктан егып алды, әмма ПЦР-тест та, компьютер томографиясе дә берни күрсәтмәде. Үземчә, «бу «омикрон»дыр», дип уйладым. Авыруның билгеләренә килгәндә, беренче көннәрдә температура югары булды. Көне буе 38,6–38,8 градус тирәсендә торды. Аякка баса алмадым, суыктан калтырандым. Коронавирус баш миенә йогынты ясады. Күзләрем нык авыртты, башым да авырайды, һәр атлаган адымым башыма чүкеч белән суккандай тәэсир итә иде. Бу вакытта: «Иммунитеты зәгыйфьрәк яисә бөтенләй иммунитеты булмаган кешеләр, хроник авырулары булганнар әлеге чирне ничек кичерә икән соң?» – дип тә уйлыйсың, – ди Михаил Любимов.

Хәзер инде ул – кабат хезмәттә. Шулай да, коронавирус эзсез генә узмаган, билгеле.

– Мин аны күбрәк беренче көнне тойдым, чын көрәш шул көнне барды. Хәзер дә тәэсирен сизәм әле. Шунысы да бар: мине нәрсә тизрәк аякка бастырды икән соң – үземнең иммунитетыммы, вакцина ясатканнан соң барлыкка килгәнеме (соңгысын өч ай элек кадаткан идем), да-

САН



Яңа дулкын җиңелрәк. Vrachu.ru табибларны дистанцион укыту хезмәте оештырган сораштыруда катнашкан медицина хезмәткәрләре коронавирус инфекциясе белән чирләү турында әнә шулай дип белдергән. Табибларның 76,1 проценты әйтүенчә, коронавирусны сырхаулар хәзерге вакытта җиңелрәк кичерә, кыен очраклар азрак. 12,7 проценты исә бу сорауга анык кына җавап бирә алмаган. Сораштыруда катнашучыларның 10,3 проценты исә сырхауларның үзгәрүен сизмәгән. 1 проценты кеше коронавирусны авыррак кичерә дип саный икән.
Шушы ук хезмәт оештырган сораштыруда катнашкан респондентларның 53,4 проценты яңадан чикләүләр кертү ихтыяҗын күрми. 28,1 проценты аларның файдасы юклыгын әйткән. 18,6 проценты исә чикләүләр авыручылар саны артуны киметә һәм аларны куллану кирәк дигән фикердә тора. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы китергән мәгълүматларга караганда, узган атнада һәр 44 секунд саен коронавирустан бер кеше үлгән.

«ОМИКРОН» БИЛГЕЛӘРЕ

2021 елның декабре, 2022 елның гыйнварында күпләрдә «кунак» булган штамм бу. Билгеләре: температура, коры ютәл, томау төшү, төчкерү, күз, буыннар сызлау, хәлсезлек, төнлә тирләү. Ис тоймау – бик сирәк очрый торган билге.

«КЕНТАВР» БИЛГЕЛӘРЕ

Бу елның августында ачыкланган штамм. Билгеләре: косасы килү һәм диарея, тамак авырту, ютәл, күз, баш сызлау, хәлсезлек, 38 градуска кадәр температура, томау төшү.

рулармы? Төгәл белəм: бу санап киткәннәрнең берсеннән дә баш тартырга кирәкми. Шулай ук боларның берсенә генә ышанып ятарга кирәк түгел. Коронавирус әле дә бар, ул грипптан, туберкулездан куркынычрак. Ул әле дә күбрәк кешеләрне аяктан ега һәм үтерә. Бу – чын, – дип кисәтә журналист.

Ясатыргамы, ясатмаскамы?

Өч елга якын коронавирус белән яшәп, бу сорауга җавап таба алмаучылар әле дә бар. Күпләрне чир йоктырып авыру түгел, укол күбрәк шүрләтә шул.

Республика Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов фикеренчә, коронавируска каршы күмәк иммунитет булдырмасак һәм аны вакыты-вакыты белән көчәйтеп тормасак, мөшкел хәлгә калуыбыз ихтимал.

– Коронавирусны вазгыять безнең һәркайсыбызга бәйле. Шул ук санитар кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне үтәү, дисенме. Вакцина ясату да шуңа керә. Ревакцинация турында күпме искә төшереп тордык. Кабат вакцина ясатырга теләк белдерүчеләр бар барын. Әмма күмәк иммунитет өчен бу сан гына җитми, – ди белгеч. – 450 меңләп кеше ревакцинация узды. Ә бит аны миллион ярым кеше узарга тиеш. Калганнары, чирләмәм, дип уйлыйдыр, мөгаен. Әмма болай уйлау аяныч тәмамланырга мөмкин шул. Прививкасыз без кабат чирнең күтәрелешенә юл куячакбыз. Яңа штаммнар барлыкка килмәс дип тә әйтеп булмый. Вирусның таралуын һәм мутациясен туктатырга кирәк.

Сүз уңаеннан, август мәгълүматларына караганда, Россиядә күмәк иммунитет дәрәҗәсе 7,4 процентны тәшкил итә.

Яңа ысул

Билгеле булганча, хәзер коронавируска каршы вакцинаны яңа төрле ысул белән ясатырга мөмкин. Бу алым назаль вакциналаштыру дип атала. Аны борынга сиптерәләр. Илнең бары тик биш төбәгенә, шул исәптән Татарстан мондый мөмкинлеккә ия.

«Спутник V» назаль вакцинасын борын куышлыгына сиптерү өчен шприцка кидерелә торган махсус җайланма – атомайзер ярдәмендә ясыйлар. Бу атнада әлеге мөмкинлектән файдалана башладылар инде. Назаль вакцинаны 200ләп кеше ясаткан. Ул шулай ук ике компоненттан тора, ике прививка арасында өч атна вакыт узарга тиеш.

– Гамалея исемендәге микробиология һәм эпидемиология фәнни үзәге мәгълүматларына караганда, назаль вакцина коронавирусның барлык штаммнарыннан да саклый, – ди Казан федераль университеты клиникасы табиб-эпидемиологы Диана Суфиярова. – Нәтиҗәләлек ягыннан караганда, вакцинаны ясату технологиясе түгел, аны ясатырга килгән кешенең халәте мөһим. Укол кадаган очрактагы кебек үк, назаль вакцинаны ясатасы кешеләрдә респиратор инфекцияләр билгеләре, вакцина ясатырга ярамау турында медицина күрсәтмәләре булмаска тиеш.

Белгечләр әлеге ысулны ревакцинация өчен кулай дип тә аңлата. Психологик яктан да мондый төр вакцина җиңелрәк. «Назаль вакцина файдалы һәм безнең республикада яшәүчеләр аны ясата ала. Җайлырак та, нәтиҗәле дә. Вакцина ясатырга кирәк», – ди Аммар Хөсәйн дә.

Пульмонолог, коронавирусны сырхаулар белән эшләүче табиб Олег Абакумов та кабат прививка ясату кирәк дигән фикердә. Чама хисен югалтмыйча гына!

– 3–6–9 ай саен вакцина ясату киңәш ителә. 65 яшьтән өлкәнрәкләр, йөрәк авырулары, тромбоз барлыкка килү куркынычы югары булган, аритмиядән, артык авырлыктан интеккәннәргә 3 айдан соң кабат прививка ясатырга тәкъдим ителә. Әмма еш кадату да яхшыга илтми. «Иммун параличы» барлыкка килмәгәе. Ягъни организмга бер үк аксым (бу очракта – вакцина) кереп торган саен, организм аны таный башлый һәм антитәнчекләр формалаштырмый. Назаль вакцина инъекциядән курыккан кешеләр өчен менә дигән. Шунысы мөһим – аны беренче вакцинагыз «Спутник V» йә «Спутник Лайт» булган очракта ясатасы. Назаль вакцина канда антитәнчекләр барлыкка китерми. Әмма аларның булганнарын куәтләп җибәрә, – ди белгеч. – Ревакцинациягә чабыгыз димим, әмма адымнарны тизләтсәк була инде. Саклану үзебез өчен кирәк.

УЗГЫНЧЫ БУЛСЫН!

Калада артса, сала да калышмый. Коронавируслы ике еллык тормышыбызда белгечләр тарафыннан бу сынамышны еш ишетергә туры килә. Әле күптән түгел генә алар, Мәскәүдә коронавирус белән авыручылар саны арта башласа, ике-өч атнадан бездә дә бу чирне йоктыручылар артачак, дип фаразлаган иде. Шулай булды да. Ә инде башкалада чир котырса, аның авылларда да баш калкытасын көт тә тор.

Мамадыш районының Усали авылында яшәүче Лидия Константинова коронавирус баш калкыткан чорга алдан аяк киенгән. Кеше яңа прививкага әле шикләнеп караган вакытта ук коронавируска каршы вакцинаны беренчеләрдән булып ясаткан ул. «Теләсә нәрсә сөйләп йөрүчеләргә караганда галимнәргә, табибларга ышандым. Үземнең ковид белән авырмавымны прививка ясатуымның файдасы дип саныйм. Безнең авылда амбулатория бар. Прививка булуга ясатам, дип, хәбәр биреп куйдым инде. Кул юып, маска киеп, саклану чараларын үтәп кенә бу чирдән котылып булмый», – дип саный Лидия ханым.

Әлегә Усалида да, күрше-тирә авылларда да коронавирус белән авыручылар күренми икән. «Мәктәбебезгә 4–5 авылдан килеп укыйлар, андый хәбәрнең әлегә ирешкәне юк. Безнең Усали авылында куркыныч беренче дулкында да, шөкер, үлем-китем очраклары булмады», – ди Лидия Константинова.

Балтач районының Кунҗр авылында яшәүче Гөлшат Шәрәфетдинова да, коронавирусның алдагы дулкыннарын авырмыйча, исән-сау гына уздыра алдык, дип сөенә. Тормыш иптәше белән икесе дә ковидка каршы вакцина ясаткан, кеше җыелган урыннарга чыкмаска тырышалар. Уңган хуҗабикә җәй буе бакчада үстергән яшелчә, җиләк-җимешне дә чиргә каршы көрәшкә җиккән. «Ел саен күп итеп кернәле, сарымсаклы помидор кабымлыгы ясыйм. Шуның да файдасын күрәбез», – ди ул. Моннан атна-ун көн элек Кунҗр авылында биш кешелек гаилә коронавирус белән җиңелчә авырып алган. Әлегә авылда башка авыручылар күренми.

Кама Тамагы районының Балтач авылы халкы да җиңел сулый. Бүген авылда бер генә ковид йоктыру очрагы да теркәлмәгән. «Шулай да әйдән бик чыгып йөрмәскә тырышам. Балалар профилактика өчен кирәкле даруларны алып кайтып бирделәр, шуларны эчәм», – ди шушы авылда яшәүче Нурания ханым Хәйруллина.

Баулы районының Мортаза авылы фельдшер-акушерлык пункты җитәкчесе Рәзинә Мөгыйнова фикеренчә, якынтирәдә ковид белән авыручылар юк, дип тынычланырга кирәкми. Әлегә аның карамагында булган 262 хуҗалыклы авылда коронавирус йоктыручылар юк икән. Әмма көзен бу чир белән авыручылар саны барыбер артачак әле, дип фаразлый ул. Өстәвенә Мортаза авылы юл чатында гына урнашкан. Шуңа күрә биреге кайтып-китеп йөрүчеләр күп. Димәк, чир таралу ихтималы да бермә-бер арта дигән сүз.

– Көзне куркып көтеп алдым инде. Коронавирус беркая да китмәде. Прививкалар аркасында коллектив иммунитет ясалды. Шуның аркасында гына коронавирус беткән кебек тоелды. Прививка бик күп кешенең гомерен саклап калырга ярдәм итте. Авыл халкы, бигрәк тә өлкәннәр арасында аңлату эшләре алып барам. Битлек киярга, урамнан кергәч, кулларны, битләрне юарга кирәклеген искәртеп торам, – ди Рәзинә ханым.

Саба районының Олы Шыңар авылы халкы бүген бераз куркуда. Ник дигәндә, күрше Миңгәр авылында коронавирус белән авыручылар күбәйгән. Шыңарда яшәүчеләрнең күбесе исә шушы авылга барып эшли. Олы Шыңар авылы фельдшеры Рузилә Мөхәммәтова сүзләренә караганда, әлегә авылда ковид белән авыручылар күренми. Җәйне дә тыныч уздырганнар. Гыйнвар – май аралыгында исә авылда 28 кеше коронавирус белән авырган. Рузилә ханым 700дән артык кеше яшәгән авыл өчен моны бик зур сан түгел дип саный. Коронавирусның көзгә яңа дулкынын да шулай җиңелчә уздырырбыз, дип өметләнә ул.

– Хәзер коронавирус төрле кешедә төрлечә уза. Кайберәүләрнең тән температурасы 39 градуска кадәр күтәрелә, башы авырта. Күп кешенең авырту тамактан башлана. Йөткергәндә какырык күпмыйча тилмертә. Купкан очракта да йөткерү озакка бара. Балаларда коронавирус косу, эч китү кебек билгеләре белән уза. Соңгы арада коронавирус вакытында колак, борын кырыена герпес чыгып тилмерүчеләр дә булды, – ди Рузилә Мөхәммәтова. – Соңгы арада шуңа игътибар итәм: кеше хәзер ковидка беренче вакытлардагы кебек куркып, паникага бирелеп карамый. Алдан даруын да алып куя. Шуңа күрә быел ковид котырган чорны җиңелрәк уздырырбыз дип өметләнәм.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Нишләргә?

Хәзер инде чир авызлыкласа, «Нишләргә?» дигән сорауга җавап эзләп карыйк. Дөресрәге, хәтердән җуелган кагыйдәләрне искә төшерик.

➤ Коткыга бирелмәү һәм дәваланмау – икесе ике төрле төшенчә. Үзең турында уйламыйча, «әйдә ярый»га таяну да, үз белдегеңнән дәвалану да начар. Даруны да, дәвалану ысулларын да бары тик табиб кына билгели ала. Шуңа күрә 112, 103 номерларына һәм теркәлү урыны буенча медицина оешмаларына шалтырату зыян итмәс. Ярдәм «кайнар элемтә» телефоны – 8-800-2000-112.

➤ Хастаханәгә барырлык хәлегез булса, йогышлы авырулар өчен махсус кабул итү боксына мөрәҗәгать итәргә (башка авырулар янында йөрмәү хәерле), тиешле анализлар тапшырырга.

➤ Иммунитетны ныгыту турында онытмаска. Күп итеп су эчәргә, аксымга бай ризыклар ашарга (үгез, куян, күркә, тавык ите), баллы тәм-томнар турында онытып торырга, булгур, карабодай, дөгене рационга кертергә, омега-3 витаминына бай балыкларга өстенлек бирергә, яшелчә ашарга. Яшел чәй, цинк, Д витаминын эчәргә.

➤ Йокы – теләсә кайсы авыру өчен кулланыла торган төп дару. 8 сәгать булырга тиеш ул.

➤ Антиоксидантлар эчү (белгечләр белән киңәшләшеп, әлбәттә).

➤ Нәтиҗәлелеге исбатланмаган ысуллар кулланып дәваланмаска (озак итеп мунчада утыру, БАДлар, антибиотиклар эчү, спиртлы эчемлекләр куллану, сарымсак ашау, тоз эремәсе белән тамак чайкау һ.б.).

12 сентябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 16.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА – ТОВАРИЩИ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ ГАСТРОНОМ ЭШЕ». (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
17.00 «Татарлар» 12+
17.30 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Динамо» (Мн). Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Каравай». Народный вокал 6+
00.15 «Таяну ноктасы» 16+
01.05 «Ком сәгате» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05, 18.20 «Җаным тулы музыка». Харис Нигъмәтҗановның иҗат кичәсе 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.20 «Җаным тулы музыка». Харис Нигъмәтҗановның иҗат кичәсе 6+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә»(субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «МОСГАЗ. ДЕЛО №8: ЗАПАДНЯ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «МОРОЗОВА» 16+
02.50 «СРОЧНО В НОМЕР!» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.35, 14.50 Новости
06.05, 19.15, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 12.40, 04.50 Специальный репортаж 12+
09.35 «СОБР» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 Матч! Парад 16+
13.30, 14.55 «ЛИЧНЫЙ НОМЕР» 12+
15.50 «Громко». Прямой эфир
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Салават Юлаев» (Уфа) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
19.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Нефтехимик» (Нижнекамск) – «Торпедо» (Нижний Новгород). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Чемпионат Италии. «Эмполи» – «Рома». Прямая трансляция
00.25 Тотальный футбол 12+
00.55 Регби. PARI Кубок России. 1/2 финала. «Локомотив-Пенза» – «Енисей-СТМ» (Красноярск) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «АГЕНТ» 16+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Остросюжетный сериал «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА. БОЛЬШОЙ ПЕРЕДЕЛ» (S) 16+
21.40 Остросюжетный сериал «РИКОШЕТ» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
01.50 «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.20 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». «Гостья из тени» 16+
14.05 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.10 «ВОЗВРАЩЕНИЕ». 1-я – 4-я серии 16+
19.00 «УРОКИ СЧАСТЬЯ» 16+
22.45 «Порча». «Старший сын» 16+
23.50 «Знахарка» 16+
00.25 «Верну любимого» 16+
00.55 «Понять. Простить» 16+
01.50 «Тест на отцовство» 16+
03.30 «Давай разведёмся!» 16+
04.20 «ЖЕНСКАЯ КОНСУЛЬТАЦИЯ» 16+
06.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «ОХОТА НА АСФАЛЬТЕ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.20 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». «ТРУДНАЯ ОСЕНЬ» 12+
10.40, 18.15 «Спец. репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 14.05 «Битва за Севастополь». Док. сериал 16+
14.00 Военные новости 16+
15.55 «Москва фронту». Док. сериал 16+
16.25 «Битва оружейников». Док. сериал 16+
18.50 «Карибский кризис. Оцифрованная история». Док. сериал. «Свободная Куба». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Климатическое оружие. Реальность или вымысел» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.30 «СВИДЕТЕЛЬСТВО О БЕДНОСТИ» 12+
01.35 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+
03.00 «Оружие Победы» 12+
03.15 «ИЗ ПЛАМЯ И СВЕТА…» 16+

13 сентябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА – ТОВАРИЩИ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ ГАСТРОНОМ ЭШЕ». (Татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 6+
21.00 «Чёрное озеро» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Виктор Несмелов. Наука о человеке 12+
00.40 «Каравай» 6+
01.05 «Уроки истории». Концепция национально-государственного устройства татар 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00 «Татар халык җырлары» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Галәм илчесеннән хәбәр бар». Габдулла Тукай турында телеочерк 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
18.20 «ГАЛӘМ ИЛЧЕСЕННӘН ХӘБӘР БАР». Габдулла Тукай турында телеочерк 6+
19.10, 21.25, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
22.20 «Татар әдәбияты дәресләре» 6+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «МОСГАЗ. ДЕЛО №8: ЗАПАДНЯ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «МОРОЗОВА» 16+
02.50 «СРОЧНО В НОМЕР!» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.35, 14.50 Новости
06.05, 14.20, 17.00, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 12.40, 04.50 Специальный репортаж 12+
09.35 «СОБР» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 Автоспорт. Чемпионат России по дрэг-рейсингу 0+
13.30 Смешанные единоборства. UFC. Лучшее 16+
14.55 Футбол. ФОНБЕТ Кубок России. «Пари НН» (Нижний Новгород) – «Химки» (Московская область). Прямая трансляция.
17.25 Футбол. ФОНБЕТ Кубок России. «Динамо» (Москва) – «Ахмат» (Грозный). Прямая трансляция
19.30 Футбол. Лига чемпионов. «Виктория» (Чехия) – «Интер» (Италия). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. «Бавария» (Германия) – «Барселона» (Испания). Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. «Ливерпуль» (Англия) – «Аякс» (Нидерланды) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «АГЕНТ» 16+
05.05 «Наши иностранцы» 12+
05.30 «Правила игры» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА. БОЛЬШОЙ ПЕРЕДЕЛ» (S) 16+
21.40 «РИКОШЕТ» (S) 16+
00.00 «РУССКИЙ РАСКОЛ» (S) 16+
01.50 «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.20 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». «Мёртвая невеста» 16+
14.05 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.10 «ВОЗВРАЩЕНИЕ». 5-я – 8-я серии 16+
19.00 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА САНТЕХНИКА» 16+
23.00 «Порча». «Без рук» 16+
00.05 «Знахарка» 16+
00.40 «Верну любимого» 16+
01.10 «Понять. Простить» 16+
02.05 «Тест на отцовство» 16+
03.45 «Давай разведёмся!» 16+
04.35 «ЖЕНСКАЯ КОНСУЛЬТАЦИЯ» 16+

ЗВЕЗДА

04.40 «ИЗ ПЛАМЯ И СВЕТА…» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.20 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». «НАПАДЕНИЕ» 12+
10.55 «Москва фронту» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.25, 14.05 «ТАНКИСТ» 16+
14.00 Военные новости 16+
17.15 «Легенды госбезопасности». «Геннадий Зайцев. «Альфа» – моя судьба» 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Карибский кризис. Оцифрованная история». «Спасение мира» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» 12+
00.45 «ТРЕВОЖНЫЙ МЕСЯЦ ВЕРЕСЕНЬ» 12+
02.15 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ…» 12+
03.40 «Перелом. Хроника Победы». Док. сериал 16+
04.05 «АНАКОП» 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 12–18 СЕНТЯБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Фикерләрегезне тәртипкә салып, үзегездән мөмкин булмаганны таләп итүдән туктагыз. Кайбер теләкләрегезнең гамәлгә аша башлавын күреп сөенерсез. «Үзеңнән соң күперләрне яндырырга ярамый» дигән гыйбарәне бик вакытлы искә төшереп, нәкъ шулай эшләрсез.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Бу атнада барысы да искиткеч дәрәҗәдә уңай килер. Сезне күрерләр һәм ишетерләр. Ләкин игътибар үзәгендә булуыгызны, димәк, көйсезлекләрегезне түгел, ә сәләтегезне күрсәтергә кирәклеген онытмагыз.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Көндәлек эшләрегез җырлап барыр. Әйбәт кенә табыш керер. Үзегезнең, чыннан да, бик кирәкле кеше булуыгызны дәлилләрдәй хәлләр килеп чыгар.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Туганнарыгыз белән мөнәсәбәтләрне тагын да җылытырдай вакыйга көтегез. Бик файдалы яңа элемтәләр корып җибәрәчәксез. Атна ахырында матди хәлегезнең яхшыруына өмет чаткылары уятырдай яңалыклар ишетерсез.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Мәшәкатьле, ыгы-зыгылы атна. Иң кирәкле эшләрегездән башлагыз, кирәкмәсрәкләрен калдырып торыгыз. Проблема чыгуын теләмәсәгез, җитәкчегез белән сүзгә килмәгез.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Эштә дә, өйдә дә тынгысызрак чор. Хезмәт хакы мәсьәләсендә бераз тавыш чыкмагае. Ләкин борчыласы юк: ахыр чиктә барысы да сез теләгәнчә булыр.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Күптәннән башыгызны авырттырып йөргән бер мәсьәлә көтмәгәндә генә искиткеч уңышлы хәл ителер. Бу үзегезне бик бәхетле кеше итеп тоюга китерү генә түгел, карьера баскычыннан югарырак үрмәләүгә дә этәргеч бирер. Ял көннәрендә дусларыгызга бәйле сәеррәк яңалыклар ишетелер.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Уңышлы чор. Атна башында әйбәт кенә керем, шәп яңалыклар һәм күңелгә хуш килердәй очрашулар көтегез. Өстәвенә әле хыялыгызда йөргән бер эш тә тәкъдим итәрләр кебек.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Юлыгызда күптәнге танышыгызны очратып, аннан үзегез өчен кирәкле мәгълүматлар ишетерсез һәм аларны мыегыгызга чорнап куярсыз. Бердәнберегез бик затлы бүләк белән сөендерер. Акчага бәйле кыенлыклар, ниһаять, артта калыр.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Четерекле хәлләрдән җиңел генә чыгып, җитәкчегезнең мактау, хуплау сүзләренә күмелерсез. Кыенлыкларны җиңү сезгә искиткеч зур канәгатьлек хисләре китерәчәк! Ләкин үзсүзләләнеп кенә маташмагыз, юкса абруегыз төшәргә мөмкин.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Эшләрегез күп булганлыктан, кайсын карарга белмәссез. Ләкин тиз генә арада ярдәмчеләр табып, барысын да көйләрсез. Әйбәт кенә премиягә өметләнүгә җирлек барлыкка килер.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Атна башында күңелегезгә кирәкмәгәнрәк уйлар үтеп керер. Ничек кенә булса да, эшегезне алыштыра күрмәгез. Абруегызның үсүенә китерердәй хәлләр көтегез.

КОТЛЫЙБЫЗ

Төбәкара хезмәттәшлекне ныгытудагы казанышлары һәм Чирмешән муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасының Чирмешән муниципаль районы башлыгы **Дәүләтшин** Фердинат Мидхәт улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Балык Бистәсе муниципаль районының социаль-икътисадый һәм мәдәни үсешенә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы **Таҗетдинов** Илдар Рәшит улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Космылина** Луиза Гариф кызы, «Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районының Ушу федерациясе» җирле иҗтимагый спорт оешмасы идарәсе рәисе **Тимофеев** Юрий Валерьянович **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Азнакай җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте бухгалтеры **Әхмәтова** Гөлфидә Кәшиф кызына, «Жилкомсервис» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры (Чаллы шәһәре) **Исаев** Илдар Роберт улына, «Спас коммуналь челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык хуҗалыгы мастеры **Самышев** Александр Геннадьевичка, «ЖИЛКОМБЫТСЕРВИС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Хәкимов** Альберт Данис улына **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БУЫННАР ШЫГЫРДАСА...

Бүген Җир шарында яшәүчеләрнең 30 проценты буын авыруларыннан интегә. Соңгы арада алар яшәрә бара, дип чаң суга белгечләр. Аз хәрәкәтләнү, дөрес тукланмау нәтиҗәсе бу. Буын авырулары тагын ни сәбәпле пәйда була? Алардан тулысынча котылып буламы?

Чаллы шәһәренең Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе табиб-травматологы Булат ЗАКИРОВ шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Булат Ирекович, соңгы арада буын авырулары ни сәбәпле күбәйде?

– Күпләр буын авырулары өлкәннәрдә генә күзәтелә дип саный. Әмма бу – ялгыш фикер. Соңгы арада тормышыбыз аеруча зур тизлек белән уза. Вакыт җитмәү аркасында дөрес тукланырга да вакыт калмый, экстремаль спорт төрләре дә модага әверелеп бара. Шул рәвешле яшьләрнең буыннары да бик тиз сафтан чыга, җәрәхәтләнә. Буын авырулары артуга соңгы елларда телдән төшмәгән коронавирус та гаепле. Ковид белән авырып терелүчеләр арасында аннан зарланучылар шактый. Бүген ковидның буыннарга тискәре йогынты ясавы хәтта фәнни яктан дәлилләнгән.

:: Буыннар ни сәбәпле шыгырдый?

– Бүген яше-карты буыннар шыгырдаудан зарлана. Ләкин бу ниндидер хилафлык, авыру бар дигән сүз түгел әле. Беренчедән, ул кеше чүгәләгәндә яки бармак шартлатканда буыннардагы газсыман куыкчыклар шартлау аркасында пәйда була. Бу хәл өлкәннәр арасында аеруча еш күзәтелә. Яшь барган саен, буыннар сыгылмалылыгын югалта, сеңерләр ката, шуңа күрә хәрәкәтләнгәндә буыннар шыгырдаган тавыш чыга. Ул буын сыекчасы азаю, физик активлык кимү аркасында да пәйда булырга мөмкин. Шыгырдаган вакытта буыннар авыртмаса, анда кызарган, шешкән урыннар булмаса, хәрәкәтләнгәндә кыенлыклар тумаса, борчылырга сәбәп юк. Алда телгә алган билгеләр күзәтелгән очракта, буынның кимерчәге тузып, кешедә артроз башланган булырга, буынның эчендә башка хилафлыклар күзәтелергә дә мөмкин. Бу билгеләр имгәнү, җәрәхәтләнүдән соң барлыкка килсә, аеруча игътибарлы булу сорала. Андый чакта кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Күпләребезгә яхшы таныш артрит, артроз һәм остеопороз бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Артроз буыннарның дегенератив зарарлануыннан гыйбарәт. Кагыйдә буларак, әлеге авыру вакытында буыннар арасындагы кимерчәк сафтан чыга. Кешегә хәрәкәтләнү авырлаша, буыннарда кискен авырту сизелә. Артроз еш кына өлкән яшьтәге кешеләрдә күзәтелә.

Артрит вакытында буыннар авыртып кына калмый, анда кызарган, шешкән урыннар да пәйда була. Еш кына кешенең температурасы да күтәрелә. Ул, гадәттә, организмга инфекция эләгү, иммун системасындагы хилафлыклар, матдәләр алмашы бозылу аркасында пәйда була. Подагра (тоз утыру), ревматоидлы артрит, реактив артрит дип аталган төрләре бар.

Остеопороз – скелет авыруы. Андый чакта сөякнең ныклыгы кими, ул уалучанга әйләнә. Остеопороз нәселдән күчәргә мөмкин. Аның килеп чыгуына кешенең яшәү рәвеше, физик активлык, организмның картаюы да сәбәпче булырга мөмкин. Еш кына кеше үзендә мондый авыру барлыгын белмичә дә яши. Сөяк сынгач кына аңлап ала.

:: Буыннар сәламәт булсын өчен, күбрәк койка, желатин ашарга кирәк, диләр...

– Алар, дөрестән дә, сөякләр, тән тиресе, тырнак, кимерчәк ныклыгы өчен кирәкле аксым – коллаген чыганагы. Организмга эләккән аксым аминокислоталарга таркала, алар үз чиратында коллагенга әверелә. Желатин – 80 проценты әнә шундый вак кисәкләргә вакланган терлек аксымы. Аны сатып алганда, составына игътибар итегез. Өйдә ясалган койка (холодец) шулай ук – коллаген чыганагы. Ул табигый чималдан ясалган булса, билгеле.

vk.com

БУЫН АВЫРУЛАРЫН КИСӘТҮ ӨЧЕН ТАБИБ КИҢӘШЛӘРЕ:

✓рационны төрләндереп, дөрес тукланыгыз;
✓спорт белән шөгыльләнгәндә, физик эш башкарганда чама хисен онытмагыз;
✓йогышлы авырулардан сакланыгыз. Авырган очракта, ахыргача дәваланып бетәргә кирәк. Ангина белән кариеска да бармак аша карарга ярамый. Алар да – инфекцияле авырулар рәтендә;
✓буыннарны һәрчак җылыда тотыгыз. Һава торышына карап киенегез, туңудан сакланыгыз;
✓имгәнү, җәрәхәтләнүләрдән дә сакланыгыз;
✓күбрәк чиста су эчегез;
✓гәүдә авырлыгын да һәрчак контрольдә тотыгыз.

:: Соңгы арада желе рәвешендәге коллагенны сатып алып ашау да модага әверелде. Ул ни дәрәҗәдә файдалы?

– Рационны төрләндереп, дөрес тукланган очракта, сау-сәламәт кешегә тик торганда коллаген ашауның кирәге юк. Ул ризык белән организмга җитәрлек дәрәҗәдә керә. Желе, капсула, порошок формасындагы коллаген ит ашамаучы вегетарианнарга файдалы. Аны буын авырулары булган, буыннары җәрәхәтләнгән кешеләр дә курыкмыйча эчә ала. Шунысын да истән чыгармаска кирәк: мондый төр коллагенны табиб белән киңәшләшкәч кенә эчәргә ярый. Белер-белмәс кулланган очракта андый коллаген, киресенчә, сөякләрнең ныклыгын киметергә мөмкин. Шуңа күрә йорт шартларында ясалган койка белән ит ашавың күпкә хәерлерәк.

:: Бүген күпләр, үзен азаплап диярлек, төрле күнегүләр ярдәмендә ябыгырга, гәүдәсен формада тотарга тырыша. Чүгәләү, алга иелү кебек күнегүләр буыннарга зыян китермиме?

– Кешенең сәламәтлеккә файдалы яшәү рәвеше алып баруы бик яхшы. Әмма бүген еш кына шундый күренешкә тап буласың: кеше, беренди әзерлексез спорт залына килеп, белер-белмәс төрле күнегүләр ясый башлый, рекорд куярга тырыша, шул рәвешле үзенең тирәк-хәрәкәт аппаратына зур зыян сала. Тренировка тәнне җылытучы күнегүләрдән башланырга тиеш. Аларны кабаланып ясый башларга ярамый. Шуңа күрә спорт залында белгеч күзәтүе астында шөгыльләнү хәерле. Буын авырулары булган кешеләргә спорт белән шөгыльләнә башлар алдыннан иң элек табиб белән киңәшләшергә кирәк.

Дару – кул астында

Үзебезне начар хис итә башлауга, тизрәк даруга үреләбез. Ә бит бу очракта кул астындагы күп кенә үлән, азык-төлек тә ярдәмгә килә ала. Белеп файдаланганда, алар да дару кебек нәтиҗә бирә.

Файдасы	Нәрсәдә бар?
Авыртуны баса	чәй, имбир, бөтнек һәм канәфер мае
Антибиотиклар	суган, сарымсак, алма, керән, чөгендер, зәйтүн мае, гәрчич орлыгы
Кан басымын төшерә	сельдерей, грейпфрут, җитен мае, каен согы, мүк җиләге
Йоклата торган	бал, җылы сөт, әфлисун кабыгы
Ашказаны авыртканнан	кәбестә, банан, яшел чәй, инҗир
Иммунитетны ныгыта	сарымсак, йогырт
Кәефне күтәрә	какао, груша, бал, имбир

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Абау!

Гырламаган «бишле» ала

Немец галимнәре йоклаганда гырлаучы укучылар белән аларның мәктәптәге уңышлары арасында турыдан-туры бәйләнеш булуын ачыклаган. Педиатрия шифаханәсе профессоры Эккехарт Падис болай аңлата: «Гырлаган балаларның баш миенә кислород бик аз күләмдә килә, шуңа күрә алар мәктәп фәннәрен бик начар үзләштерәләр». Гырлау сулыш алуны чикләгәнлектән, кеше организмына үпкәдән керә торган кислород җитми башлый. Бу исә баш миенә эшләргә комачаулый. Шуңа да илледән артык чирнең барлыкка килүенә сәбәпче булып тора икән. Ярый әле аларның күбесе, гырлауның үзе кебек үк, дәвалауга биреш. Гырлаудан дәваланган балаларның мәктәп билгеләре дә ике баллга күтәрелгән.

Үзем сынадым

Салкын тимәсен, дисәң...

Салкын тию, грипптан саклану өчен, көзен шушы төнәтмәне ясап куям. Ярты литр кайнаган суга вакланган ярты лимон белән 6–8 тырнак сарымсак салам да шуны 2–3 көн бүлмә температурасында караңгы урында төнәтәм. Бу төнәтмәне һәр иртә ач карынга бер аш кашыгы эчәбез. Балаларга бер чәй кашыгы бирәсе.

Халисә САТТАРОВА.
Арча

Валентина СЕМЕНОВА

ВИТАМИНЛЫ КЫШ

vk.com

Көзге, кышкы сортлы алмалар өлгереп бетте диярлек. Озакламый кызыл, кара миләшне җыя башлаячакбыз. Бу витамин сандыкларын әрәм-шәрәм итмичә, кышка ничек сакларга? Әлеге сорауга тәҗрибәле бакчачы Виталий Дмитриев җавап бирде.

Алма, дисәң дә, алалар...

Виталий Михайлович әйтүенчә, сортын белеп, агачыннан дөрес җыеп алганда һәм саклау шартларын үтәгәндә, берничә ай буе үзең үстергән алмалар белән сыйланырга мөмкин. Җәйге сортлар («Яблочный спас», «Грушовка московская», «Масловское» һ.б.) ике атнадан ай ярымга кадәр саклана. «Волжская красавица», «Коричное новое», «Орловское полосатое», «Шафран Саратовский» кебек көзге сортлар декабрь башына кадәр бозылмый. Кышкы сортлар («Антоновка обыкновенная», «Анис розовый», «Башкирский красавец», «Ренет татарский») шактый озак – 2–3 ай саклана. Ә «Богатырь», «Московское позднее», «Синап орловский» кебек сортларны апрель аена кадәр саклап була.

Иң элек алманы дөрес җыярга кирәк. Агачтан алганда, кабыгына зыян китерсәң, алманы озак саклап булмый. Авыруларга тиздән бирешүче иске сортлар кутыр авыруыннан (парша) зыян күрә. Бәрелмәгән-изелмәгән, кутырсызларын гына саклауга кую әйбәт. Иң элек алмаларны, йогышсызландыру өчен, алсу төстәге марганцовка эремәсендә тотыгыз һәм әйбәтләп киптерегез. Һәркайсын кәгазьгә төреп, тартмага пычкы чүбе, вакланган салам яки карабодай кабыгы белән аралаштырып тезегез. Саклауга куярга 10–15 көн кала, салкынча ачык урында тотыгыз. Алмалы әрҗәләрне температурасы 0–5 градус, һава дымлылыгы 80–90 процент булган урынга (баз, подвал яки идән астына) урнаштырыгыз. Дымлылык дәрәҗәсе төшсә, сулы чиләк куярга мөмкин. Алманы башка яшелчәләр һәм бәрәңге белән бергә сакларга ярамый.

Кайбер сортлар полиэтилен капчыкта да саклана. Әмма кайвакыт «Антоновка» капчыкта күрән таплар белән каплана. Шуңа күрә аны башта вазелин сеңдерелгән чүпрәккә төреп кую хәерле.

Тагын шунысы мөһим: черек кергән алмаларны шундук алып ташларга һәм шуннан соң кулларны сабынлап юарга кирәк. Черек споралары кулдан сәламәт җимешләргә күчәргә мөмкин чөнки.

Кара миләшне юмаска

Кара миләшкә килсәк, файдалы матдәләре күбрәк сакланып калсын өчен, җимешне киптерәләр яки катыралар. Ике ысулы да бик гади, ди Виталий абый. Ачык һавада да, газ мичендә дә киптерергә мөмкин. Ләкин киптерер алдыннан юарга ярамый. Кипкән җимешләрне кулланыр алдыннан гына юып алалар. Киптерү өчен, җимешләрне юка катлам итеп, подноска яки такталарга тезәбез. Җимеш тәлгәшләрен җеп белән бәйләп, элгән килеш тә киптерергә мөмкин. Ачык һавада киптергән очракта, тартмага салып, сакларга куяр алдыннан минималь температурада (40 градус чамасы) 15–20 минутлап газ мичендә киптереп алу зыян итмәячәк. Ник дигәндә, кибеп җитмәгән очракта, җимешләр бик тиз күгәрә.

Газ мичендә киптерү өчен, кара миләшне калай табага бер рәт тезәбез. Көймәсен һәм табага ябышмасын өчен, мич ишеген бераз гына ачык калдырабыз. Мич температурасын 40 градус итеп куябыз. Киптергәннән соң кара миләш үз төсен саклап калырга тиеш. Кызгылт яки көрән төскә керсә, җимеш артык кибеп киткән, дигән сүз.

Кызыл миләшне кайберәүләр кырау төшкәч кенә җыя. Әйе, суык алган җимешнең әчесе югала, тәмлерәк була. Ләкин ул тиз бозыла. Шуңа күрә кырау төшкәнче җыеп алу хәерлерәк. Аларны тәлгәшләп яки тәлгәшләреннән аерып саклыйлар. Миләш суыткычта катырмаган килеш 1–2 ай саклана. Ә катырылган хәлдә бер ел дәвамында үзенең файдалы сыйфатларын югалтмый.

Киптерү ысулын сайлап алган очракта, газ миче ишеген бераз ачып, 50–60 градус температурада киптерәбез, әледән-әле болгаткалап торабыз. Шулай ук ачык һавада да киптерергә мөмкин. Кипкән миләшне пыяла банкага, кәгазь яки тукыма капчыкка тутырып, саклауга куябыз.

ВИТАЛИЙ ДМИТРИЕВТАН РЕЦЕПТЛАР

Маринадлау

Кара миләшне юып, пыяла яки эмаль савытка тутырабыз. Маринад ясыйбыз: бер литр суга бер аш кашыгы шикәр комы, ярты чәй кашыгы йодсыз тоз, 2–3 канәфер, бер чеметем дарчин (корица) салып кайнатабыз. Суынганнан соң җиләкләр өстенә агызабыз.

Бал кушылган миләш

Мондый ысул миләшнең файдалы үзенчәлекләрен тулысынча саклау мөмкинлеге бирә. Миләшне юып, иттарткыч аша чыгарабыз яки блендерда ваклыйбыз. Шуңа 1:2 нисбәтеннән бал яки шикәр комы өстибез. Балы яки шикәре эреп беткәнче болгатып, парландырылган банкаларга тутырабыз. Кайнатманы суыткычка яки башка салкынча урынга куеп саклыйбыз.

Укучы киңәше

Кәбестә урынына шалкан утыртма

Туталләрдә кәбестә өлгереп килә. Киләсе елга аның урынына нәрсә утыртырга икән, дип уйлап йөрим әле. Тәҗрибәле бакчачы булганлыктан, шуны бик яхшы беләм: кәбестә урынын һәр ел саен алыштырып торырга кирәк. Юкса уңыш күрмәячәксең. Ник дигәндә, туфрактагы туклыклы матдәләрне күп микъдарда үзенә суырып, аны бик нык ярлыландыра ул. Моннан тыш, зарарлы корткычларны, өнчыл чык кебек авыруларны да үзенә җәлеп итә.

Кәбестә тамыры туфракның урта катламында «яши». Димәк, аның артыннан тамыры тирәнгә китә торган яки, киресенчә, туфракның өске катламында гына урнаша торган яшелчәләрне утыртырга кирәк. Кыскасы, кәбестәдән соң бәрәңге, баклажан, кыяр, ташкабак, патиссон, кишер, чөгендер, петрушка, суган утырту әйбәт. Ә менә редис, шалкан, яфраклы горчица, шулай ук помидор начар үсәчәк.

Фирая ХӘЕРОВА. Саба районы

Бакчачы почмагы

Сорауларга бакчачы Эльмира ИСХАКОВА җавап бирә

Гортензияне кисәргәме?

? Язын себеркесыман гортензия утырткан идем. Әйбәт кенә үсеп китте. Кышка аны ничек әзерләргә: ботакларын кисеп, капларгамы икән?

Наилә САБИРОВА. Балык Бистәсе

– Тамырлары ныгып китсен өчен, утырткаппан соң беренче ике елда кисмәскә, ләкин яшь үсентене кышка чыршы ботаклары белән каплап калдырырга киңәш ителә. Ә инде гомумән алганда, гортензияне көзен яфраклары коелып беткәч һәм яз көне – су «эчә» башлаганчы кисәргә кирәк. Ботакны тышка таба караган бөре өстеннән кисү шарт. Эчкә таба караганы өстеннән киселсә, ботак үзәккә таба үсәчәк. Куе булмасын өчен, гортензиянең үзәктәге ботагын, шулай ук җиргә авышкан, зәгыйфь ботакларын кисәләр. Нечкәрәк ботакларда – 2 бөре, калганнарында 4 бөре калдырып кыскартыла.

Зур үсенте суыкка чыдам була, шуңа күрә кышка ябып калдыруны таләп итми.

Слива өлгерми, нишләргә?

? Сливалар өлгереп җитмәде әле. Төннәрен кырау да төшкәли башлады инде. Җыеп куйсак, тартмаларда пешеп җитәрме икән?

Лилия ГАЛИЕВА. Биектау районы

– Ник коелмаса, өзәргә ашыкмагыз: өлгерергә вакыт бар әле. Агачта пешкәне барыбер тәмлерәк бит. Җыеп куярга да була анысы: тартмада өлгереп җитәчәк, ләкин тәме генә кайтышрак булачак.

Хуҗабикәгә

КОМПОТ СЕРЕ

Кипкән җимешләрдән компот әзерләү барышында шикәр комы салырга кирәкми. Кәстрүлдәге компотны уттан алгач, 15 минут тотыгыз. Шуннан соң төмен татып карагыз. Татлы булмаса гына, бераз шикәр комы өстәгез. Җимешләр, бераз торганнан соң, компотка үзләренең татлы төмен чыгара.

Тәмле булсын!

КЕРӘНЛЕ ПОМИДОР

Резедә Шәрәфиева рецепты

Кирәк булачак: 2,5 кг помидор, 0,5 кг татлы борыч, 0,1 кг әче борыч, 0,5 кг кишер, 1 стакан шикәр комы, 0,5 стакан тоз, 0,5 стакан серкә, 150 грамм керән тамыры, 150 грамм сарымсак.

Яшелчәләрне иттарткыч аша чыгарабыз. Барлык ингредиентларны бергә кушып болгатабыз. Чиста банкаларга тутырып, суыткычка куябыз. Бозылмый торган бик тәмле кабымлык!

БЕР РӘХӘТНЕҢ МЕҢ МИХНӘТЕ

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Кем дә кем ике ирене һәм ике аягы арасындагы әгъзаларын хәрамнан тыйса, мин ул кешегә җәннәтне вәгъдә итәм», – дигән. Шул рәвешле диндә зина олы гөнаһ буларак бәяләнә. Әмма, ни кызганыч, бүген бу яман күренеш гадәти күренешкә әверелеп бара. Зина кылучыны нәрсә көтә? Бу гөнаһтан тәүбәгә килеп кенә котылып буламы?

«Рөстәм» мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН белән шул хакта сөйләштек.

:: Исмәгыйль хәзрәт, адәм баласы зина турынданиләр белеп торырга тиеш?

– Зина – никахсыз җенси мөнәсәбәткә керү. Ислам динендә ул катгый тыела. Зина алдашу, урлау, кеше үтерү кебек гөнаһлар арасында иң түбән, фәхеш гөнаһлардан санала. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Зинага хәтта якынаймагыз», – ди. Ул җәһәннәмгә, кабахәтлеккә алып бара торган юл булып тора. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә: «Әгәр бер мөселман кеше зина кылса, шулвакыт аның иманы аннан күтәрелеп тора», – диелә. Ник дигәндә, иман, шушы чиста хис, Аллаһка ышану зиначы кеше белән бер тәндә була алмый. Шул ук вакытта пәйгамбәребез икенче бер хәдисендә: «Әгәр дә халык арасында зина таралса һәм шушы зина ачыктан-ачык гадәти хәлгә әверелеп китсә, шулвакыт кешеләр арасында моңарчы күрелмәгән чирләр таралачак, эпидемия шикелле күренешләр булачак», – дигән. Кызганыч, хәзерге заманда зина кайчак гөнаһка да чутланмый. Шул ук вакытта Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Әгәр кеше бу дөньяда башка кешенең гомерен өзсә, Аллаһны танымаса, зина белән шөгыльләнсә, шулчак бу дөньяда һәм ахирәттә өстәмә газаплар киләчәк», – ди. Зина кылудан тыелып калган кеше кыямәт көнендә Аллаһы Тәгаләнең гаршене – тәхетенең күләгәсе астында булачак.

:: Ир-ат зина кылса, «ир-атка ярый, аның табигате шундый» дигән сүзне еш ишетергә туры килә. Ир-атның табигате шундый дип, гөнаһларын шулай каплап йөрү дөресме?

– Зина кылган ир-ат та, хатын-кыз да шәригать буенча бер үк дәрәҗәдә гөнаһлы санала. Зина кылучы ир-ат булсынмы, хатын-кыз булсынмы, аларның гади мөселманнарга өйләнергә, кияүгә чыгарга хаклары юк. Алар үзләре кебек зиначы яки ислам динендә булмаган башка кеше белән генә гаилә корырга тиеш. Коръәннең бер сүрәсендә шулай диелә. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Әгәр дә сез телегезне, җенси әгъзагызны тыя алсагыз, шулвакыт Аллаһы Тәгалә сезгә җәннәтне вәгъдә итә», – диелә. Зина мәсьәләсендә ир-атларга да бернинди искәрмә юк. Ислам динендә ир-атка ирлек, куәт ул үзенең акылын да, тәнен дә, йөрәген дә кулда тота алсын өчен бирелә. Никахлы хатыны, ире була торып зина кылган кеше тагын да түбәнрәк гөнаһ кылган санала.

:: Зинаның нинди төрләре була?

– Зина юктан гына барлыкка килми. Аңа алып бара торган юллар бар. Зинаның төрләре дә әнә шушы юллар буенча аерыла. Беренчесе – тел зинасы. Ир кеше – үзенә хәләл булмаган хатын-кыз, хатын-кыз үзенә хәләл булмаган ир-ат белән аралашу. Бер-берсенә туган тиешле кешеләргә дә җенси мөнәсәбәтләр турында сөйләшү тыела. Икенчесе – күз зинасы. Кешенең ят, гаурәт җирләренә карарга ярамый. Зинага якынайта торган хаталарның иң куркынычы – аулак урында каршы җенес вәкиле белән ялгыз калу. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Әгәр сез абыегыз яки энегезнең хатыны белән бер бүлмәдә калсагыз, бу – үлем», – ди. Ислам динендә балалар сабыйлыктан чыга башлагач, 11–12 яшьләр тирәсендә кыз һәм малайларны бер ятакка яткырырга ярамый. Зинаның дүртенче төре – аяк зинасы. Бу очракта кеше үзе зинага махсус бара.

:: Кыз авырга узгач, никах укытучылар очрый. Андый никах дөрес буламы? Бу никахта туган бала зинадан туган булып саналамы?

– Мондый никах дөрес була һәм бу бала да ата-анасыныкы, ягъни никахта туган сабый булып тора. Бала туганда ата-ана никахлашмаган булса, ул зинадан туган бала санала.

> Аллаһы Тәгалә «Әнгам» сүрәсендә: «Бер җан да икенче кешенең гөнаһы өчен йөкне күтәрмәс», – ди. Ягъни һәркем үзенең хатасы өчен генә җавап кайтара. Шуңа күрә зинадан туган баланы да берничек тә шелтәләп булмый.

Киресенчә, ислам динендә андый балалар арасында яхшы тәрбия алып, үскәч, галим булган, ислам диненә зур файда китергән кешеләр дә бар.

:: Зина кылган кыз белән егетнең гөнаһы аларны тәрбияләп үстергән ата-анага да төшә аламы?

– Әйткәнемчә, Коръәни Кәримдә: «Бер җан да икенче кешенең гөнаһы өчен йөкне күтәрмәс», – диелә. Ләкин пәйгамбәребезнең бер хәдисендә: «Кем игелеккә үрнәк булса, игелеккә өйрәтсә, әҗер-савабын алачак. Кем дә кем әшәкелек, кабахәтлеккә сәбәпче булса, үрнәк күрсәтсә, өйрәтсә, бу гөнаһның өлешен дә үзенә алачак», – диелә. Бу хәдис әти-әниләргә дә махсус бер искәрмә булып тора. Алар балаларга зинаның нәрсә икәнен аңлатмаса, гаурәт урыннарын капларга, ят урыннарга карарга ярамавын өйрәтмәсә, үзенең яшь вакытта булган кызлары, егетләре турында мактанып утырса, бу баланың зинага җиңел каравына сәбәп булырга мөмкин. Шуңа күрә ата-ана баласына тиешле дәрәҗәдә тәрбия бирмәсә, бала кылган зинаның гөнаһы ата-ана җилкәсенә дә төшәчәк. Ул үзенең баласы өчен Аллаһы Тәгалә каршында җаваплы.

vk.com

:: Зина кылган кеше тәүбәгә килсә, аның бу гөнаһы кичереләме?

– Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Зина, кеше үтерү, Аллаһка карата тиңдәш китерү кебек гөнаһлар өчен кеше бу дөньяда да авырлыгын күрәчәк. Ахирәттә дә аларга газап үсәчәк, илләдә мәгәр шул кешеләр кайсылары Аллаһ каршында тәүбә китерергә, ихластан гафу үтенергә көч таптылар», – ди. Кеше бу дөньяда нинди генә гөнаһ кылса да, аның Аллаһка кайтырга, гафу үтенергә хакы бар. Шул ук вакытта әгәр дә кеше зинага карата тәүбә китермәсә, кыямәт көнендә аны ачы газап көтә.

:: Зина кылучының гөнаһы аның җиде буынына кадәр күчеп барачак, диләр. Бу дөрестән дә шулаймы?

– Имам Шәфигый: «Бел: синең зинаң ул – бурыч шикелле. Бурычны йөртүндагы гаиләң белән кайтарырга туры киләчәк», – ди. Мөселман галимнәренең бер ише аның белән килешә, икенчеләре моңа каршы килә. Зиначы кеше гаиләсенә тәрбия бирми. Ул, киресенчә, шушы зина белән горурланырга мөмкин. Икенчедән, хатынын, балаларын зинадан сакламый. Бу да аның гаиләсе зинага керүгә бер сәбәп булырга мөмкин. Әгәр ата-ананың берәр кимчелеккә ятышлыгы бар икән, ул балаларга да күчәргә мөмкин. Һәр яңа туган сабый дөньяга чиста һәм пөхтә булып аваз сала. Аны ата-анасы боза. Хәрам ризык ашатып, каршында яман үрнәк күрсәтеп, аларга дөрес булмаган тәрбия биреп эшли алар моны.



Йөрәген чистарт!

Гыйбрәтле кыйсса

Көннәрдән бер көнне пәйгамбәребез янына бер яшь кеше килә һәм шундый үтенечен белдерә: «Йә Аллаһның илчесе, миңа зина кылырга рөхсәт бир!» Шунда булган сәхабәләр бу кешене ачулана башлыйлар. Ләкин пәйгамбәр аларны туктата һәм егеткә берничә сорау бирә:

– Әйтче миңа, егет, син башкаларның үз сеңлең белән зина кылуларын теләр идеңме?

Яшь кеше: «Юк, әлбәттә, теләмәс идем», – ди.

– Кемнең дә булса үзеңнең кызың белән зина кылуына риза булыр идеңме?

Егетнең йөзе кырыслана һәм ул ачулы рәвештә: «Юк! Мин моңа беркайчан да риза булмыйм!» – дип җавап бирә. Шул вакытта пәйгамбәрнең дә йөзе кырыслана һәм ул егеткә өченче соравы белән мөрәҗәгать итә:

– Ә син башкаларның үз әниең белән зина кылуына ничек карыйсың?

Хәзер инде егетнең ачуы тагы да кабара һәм ул, үз-үзен көч-хәл белән тотып калырга тырышып: «Юк! Мин риза түгел моңа, риза түгел!» – дип кычкыра. Шуннан соң Аллаһның илчесе хатыны, апалары, башка кыз туганнары турында сорый, ләкин егет аларның да башкалар белән зина кылуларына һич тә риза түгел икән.

Пәйгамбәребез, сорауларына җавап алганнан соң, егеткә үзе янына якынрак килергә куша да, миһербанлы кулын аның күкрәгенә куеп, дога кыла: «Йа Раббым, аның калебен чистарт һәм үзен зиналардан сакла!»

Киләчәктә бу егет беркайчан да зинага тартылмый һәм иптәшләренә: «Аллаһның илчесе янына барганчы, зина минем өчен иң ләззәтле гамәл иде, ләкин аның белән сөйләшкәннән соң, зинаны мин иң начар, иң пычрак һәм кабахәт эш дип саный башладым...» – дип сөйли.

Йәгез, бер дога!

Тәнгә эренле шеш (чуан) чыккач укыла

Аллаһуммә мотфи әль-кәбир үә мөкәббир ас-сагыйр атфиэһа ганни.

Мәгънәсе: «Аллаһым! Син зур нәрсәләрне кечерәйтәсең, кечкенә нәрсәләрне зурайтасың. Аның (чуанның) утын сүндер, миннән китәр». (Әхмәд б. Хәнбәл: 5/370).

***

Кешеләргә явызлык, усаллык кылма. Синең шулай эшләвең сиңа үзеңнән сәдака булыр. (Хәдис)

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ГӨЛЗАДА ШАКИРҖАНОВА:

«ҖЫРЧЫ БУЛСЫН ДИП, ИСЕМЕМНЕ ӘТИ КУШКАН»

Бүгенге «Ни хәл?» сәхифәсенең кунагы – Сарман сандугачы, Салават Фәтхетдинов төркемендә җырлаучы Гөлзада ШАКИРҖАНОВА. Җырга-моңга төренеп үскән кыз Салават абый белән ничек танышкан? Фирдүс Тямаев төркеменнән ни өчен киткән? Үз концертларын куярга ниятлиме? Әңгәмә әнә шулар хакында.

:: Ни хәл?
– Бар да яхшы. Салават абыйның (Фәтхетдинов. – **Авт.**) август концертларыннан соң ял иткән мәлебез әле. Тиздән тагын өч көн өстәмә концертлар куячакбыз.

:: Ничә яшьтән бирле җырлыйсыз?
– Үземне белгәннән бирле. Аңа кадәр дә җырлаганмындыр әле (*көлә*). Минем үземнән 10 яшькә өлкәнрәк апам бар. Ул да җырлый иде. Шулай берсендә безнең өйгә Зөлфия Минһаҗева җырларыннан тупланган кассета килеп эләкте. Анда караоке да бар иде. Апама кушылып, телем ачылыр-ачылмас килеш «Миләшкәем»не җырлаганым истә калган.

Мин бит – иҗади гаиләдә үскән бала. Әнием җырлый, әтием гармунда уйный. Исемне дә миңа әти: «Минем кызым җырчы булачак!» – дип кушкан. Чөнки мин туганда, Гөлзада Сафиуллина бик популяр булган. Бик сирәк һәм үзенчәлекле исем булганы өчен яраткан ул аны.

:: Сарман ягыннан булуыгыз да үзенекен иткәндер?
– Әйе! Безгә еш кына: «Сезнең чишмәгез шундыйдыр инде», – дип әйтәләр. Чыннан да, күпме талантлар биргән төбәк бит ул.

:: Исемегезне үзегез дә яратасызмы соң?
– Бүген хәтта авыру балалар мәктәптә укыганда, сәламәт балаларның өйдә укуы бик дөрес әйбер түгел. Бик авыру булса гына, өйдә укытырга мөмкин. Сәламәт баланы өйдә укытуга күчереп исә җәмгыятьтән аерабыз, тормышын чиклибез. Әле укытучысы яхшы булса, бер хәл. Өйдә укытучылар алар – нигездә, акча эшләүчеләр. Балаларга стандартларны да өйрәтергә, тәрбия дә бирергә кирәк. Ә алар нинди укытучы, белемнәре, әхлаклары ничек? Шул хакта уйларга кирәк. Укытучылар балаларны елмаеп, тыныч укытсын иде. Аларның нерв системасы болай да какшаган. Мәктәп яхшы булырга, әти-әниләр аңа ышанырга тиеш. Шул очракта гаиләдә укуга да ихтыяҗ булмаячак.

ТАТАРНЫ ЯКЛАУЧЫ АРЫСЛАН БӘК

КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМ, ЯЗУЧЫ, ТӘРҖЕМӘЧЕ ЛЕВ ГУМИЛЕВНЫҢ ТУУЫНА – 110 ЕЛ

1960 нчы елларда Лев Гумилев хатларын исеменең тәрҗемәсе белән – Арыслан бәк дип имзалый башлый. Бу факт үзе генә дә аның төрки халыкларга ни дәрәҗәдә якын булуын дәлилли. Татар халкы да аны олылый, хөрмәт итә.

Миркасыйм Госманов исемендәге Алтын Урда һәм татар ханлыкларын тикшерү үзәге җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты Илнур МИРГАЛИЕВ белән шул хакта сөйләшәбез.

:: Илнур Мидхәтович, хәтерлим әле, Казанның 1000 еллыгы алдыннан Петербург урамы башына Петр Ігә һәйкәл урнаштырырга дигән сүз чыккач, җәмәгатьчелек моңа каршы төште. Нәтиҗәдә бу дәрәҗәле урынга тарихчы галим Лев Гумилев бюстын куярга тәкъдим иттеләр. Моны хакимият тә хуплап каршы алды. Нинди фәнни ачышлары, нинди хезмәтләре белән яулады икән бу олуг галим безнең күңелләрне?

– Татар халкы Лев Гумилевның фәнни хезмәтләренә, ачышларына зур бәя бирә. Тарихчы буларак, ул Азиянең очсыз-кырыйсыз далаларында яшәгән, рус дәүләте белән тыгыз мөнәсәбәттә торган борынгы халыклар һәм дәүләтләр турында яңа тикшеренүләр, ачышлар ясап калдыра. Кем икәнлегебезне аңлатып бирә. Лев Николаевич – үз шәҗәрәсен татарларга тоташтырган шагыйрә Анна Ахматованың һәм 1921 елда «халык дошманы» дип атып үтерелгән офицер, шагыйрь Николай Гумилевның улы. Аның тарихчы, этнослар белгече, философ буларак фәнгә керткән гаять күп яңалыклары арасында дөньякүләм казаныш дип танырлык хезмәте бар. Ул – яңа этник системалар барлыкка килүне пассионарлык (милләтнең, биоэнергиясе ташып чыгу аркасында, үз-үзен саклау инстинктын югалтып, күченеп йөри башлавы) теориясе аша аңлату. Галим шуның нигезендә Азия һәм Көнчыгыш Европа киңлекләрендә төрле этносларның, шул исәптән рус, хәзәр, татар һәм башкаларның барлыкка килүен, үзара мөнәсәбәтләрен, дәүләтләр оешуны тарихи чыганаклар мөмкинлек биргән дәрәҗәдә дөреслеккә туры китереп тасвирларга тырыша. Безнең өчен аның хезмәтләрендәге Алтын Урда һәм рус дәүләте симбиозына (биологик төрләрнең бергә яшәве) багышланган өлеше аеруча кызыклы. Лев Гумилев – моңа кадәр тарих фәнендә ясалма тудырылган һәм берничә гасырлар буена яшәп килгән татар-монгол изүе турындагы уйдырманы юкка чыгаручы беренче кеше. Монысы татар халкы өчен бигрәк тә мөһим. Галимнең тарихта татар-монгол изүе дип йөртелә торган чорга биргән бу бәясе күпләрне аптырашта калдыра. Алтын Урда ханнары үз түрәләреннән яулап алынган җирләрдә салым түләүчеләрне кысмауны таләп иткәннәр, дип билгеләп үтә ул бу җәһәттән. Без – татарлар, шулай ук барлык төрки халыклар, бу олуг галимне төрки дөньяны өйрәнүе, дөреслекне курыкмыйча әйтеп бирә алганы өчен хөрмәт итәбез, олылыйбыз. Ул татарча да яхшы белгән. Бу хакта язучы Мөсәгыйть Хәбибуллинның истәлекләрендә дә язылган: «Исәнме, Кубрат хан оныгы! Әйдә, чишен дә түрдән уз. Мин татарча беләм, ундүрт ел сөргеннең файдасы татарлар тарихын өйрәнүгә китте», – дип каршы ала ул аны үз фатирында.

:: Сөргеннең файдасы дигәннән, димәк, кайда гына булса да, ул бер минутын да әрәмгә үткәрмәгән булып чыга?

– Ходай аңа талантны да, сәламәтлекне дә, бәхетне дә өеп бирә. Оптимист була ул. Фани дөнья белән дә, алдыма куйган максатка ирештем, дип хушлаша. Сиксән ел эчендә бер кандидатлык, ике докторлык диссертациясе яклый. Ундүрт монография чыгара. Егермегә якын китап, ике йөздән артык гыйльми мәкалә бастыра. Аның университеттагы лекцияләренә Ленинград халкы бәйрәмгә барган кебек йөри. Ә бит Лев Гумилев сәяси тоткын сыйфатында дүрт тапкыр кулга алына, атарга хөкем ителә, барлыгы ундүрт ел гомерен лагерьларда үткәрә. 1944 елда үз теләге белән сугышка китә. Берлинны алуда катнаша. Бер әңгәмәсендә үз тормышы турында ул: «Мин нәрсә теләдем – шул турыда уйладым, нәрсә уйладым – шул хакта яздым һәм үземнең барлык китапларымны да басылган хәлдә күрдем», – дип әйтә. Чыннан да, «От Руси до России» исемле соңгы китабының сигнал нөсхәсен хастаханәгә китерәләр. Шуннан озак та үтми галим якты дөнья белән хушлаша.

:: Совет хакимияте каршында Лев Гумилевның нинди гаебе бар?

– Шунысы кызык: истәлекләрдән күренгәнчә, Лефортово төрмәсендә тикшерүче шушы сорауны аның үзенә юллый. Гумилев: «Бернинди дә», – дип җавап бирә. Ул чорда тикшерүчеләр җинаятьне үзләре уйлап тапкан бит. Дөресме, юкмы – ул хакта башларын катырып, уйлап тормаганнар. Лев Николаевичка гаеп тагу авыр булмый үзе. Контрреволюцион гамәлләре өчен атып үтерелгән офицер, дворян улы бит. Алар уйлавынча, бәлки, ул күптән совет властеннан үч алу турында хыялланадыр. Аның «җинаяте» әнә шул була. Хәзер генә без әтисе Николай Гумилевның бер гаебе дә булмаганын, нахакка атылганын беләбез. Алар аталы-уллы икесе дә – репрессия корбаннары. Бу хәлләрдән Анна Ахматова да зыян күрә.

:: Күп кенә чыганакларда, Лев Николаевич әнисе белән тату яшәмәгән, дигән фикерләр чагылып китә...

– Тормыш иткәндә төрлесе булгандыр инде. Лев Гумилев Санкт-Петербург шәһәрендә туа. Анна белән Николай, уллары тугач та, фикердәшләре белән гадәтләнгән тормышларын дәвам иттерәләр. Малайны әтисе ягыннан әбисе Анна Гумилева тәрбияли. Бәлки, шушы хәл дә тәэсир иткәндер. Әбисенең Тверь шәһәреннән ерак түгел уз утары була. Лев анда биш ел яши. Октябрь инкыйлабы башлангач, Бежец шәһәренә күченәләр. Анна белән Николай 1918 елда аерылышалар. Лев Петербургка килә. Малай бер ел буена әтисе янынан китми. Әнисендә кунак кына була. Тиздән әтисе дә, әнисе дә яңа гаилә кора. Әбисе малайны яңадан үз янына алдыра. Лев өч мәктәп алыштыра, дуслары да булмый. Аны пионерга да, комсомолга да алмыйлар. «Халык дошманы» улыннан барысы да читләшергә тырыша. Мәктәпне тәмамлагач, 1930 елда Лев әнисе янына Ленинградка килә. Институтка керергә тели. Әмма чыгышы дворян булу сәбәпле, гаризасын кабул итмиләр. Заводка кара эшче булып урнаша. Аннан трамвай депосына күчә. Хезмәт биржасына исәпкә баскач, геология экспедициясенә өзерләнүчеләр курсына килеп эләгә. 1931 елда Байкал тирәсенә беренче сәяхәткә чыгып китә. Ул 21 экспедициядә катнаша. 1933 елда аны беренче тапкыр кулга алалар. Бу хәлләр башлангач, әнисенең ярдәме бик зур була: ул, улын ярлыкауларын сорап, Сталинга хат яза. Беренчесендә 9 көннән берниндн гаеп такмыйча чыгарып җибәргән булсалар, икенчесендә нәкъ менә әнисенең хаты ярдәмгә килә. Моны, әлбәттә, ул белән ана арасындагы мөнәсәбәтләрдә һич кенә дә вак-төяккә санап булмый. Әмма Лев Гумилевның төрмәдән коткару мәсьәләсендә әнисенә ризасызлык белдерүе турында сүзләр дә бар. Шулай булган очракта ул, мөгаен, хаклы ук түгелдер дигән фикер дә йөри. Чөнки Анна Ахматова Сталинга берничә тапкыр мөрәҗәгать итә. Барып кына чыкмый. Аннан килеп, Лев Гумилевның Санкт-Петербургтагы музей-фатирында әнисенә язган хатлары саклана. Алар хөрмәт һәм дустанә хисләр белән язылган.

:: Галимнең тормыш юлын өйрәнә башласаң, гаҗәпкә каласың. Әзәрлекләнү, бертуктаусыз кулга алынулар, сугыш... Кай арада шундый зур эшләр эшләргә өлгергән?

– Аның әдәби таланты мәктәптә үк ачыла башлый. Стена газеталарына мәкаләләр, шигырьләр яза. Көнчыгыш республикаларга экспедицияләргә йөргәндә төрки телләргә кызыксыну уяна. Ул алты телдә сөйләшә. 1935 елда Ленинград университетының тарих факультеты студенты булу бәхетенә ирешә. Белем дәрәҗәсе буенча сабакташларыннан аерылып тора. Әмма кулга алыну сәбәпле, укуын дәвам иттерә алмый. Сугыштан кайткач кына диплом алуга ирешә. 1948 елның декабрендә Гумилев төркиләр тарихы буенча кандидатлык диссертациясе яклый. 1959–1963 елларда Каспий диңгезе буенда өйрәнү эшләре алып бара. Шул материаллар нигезендә «Открытие Хазарии» китабын яза. Әлеге китапның чыгуы зур казаныш дип кабул ителә. Бу хезмәт «Хунну», «Хунну в Китае», «Древние тюрки» тетралогиясенең башлангычы була. Озак та үтми, «Поиски вымышленного царства» китабы пәйда була. Алар барысы да тиз арада чит телләргә тәрҗемә ителә һәм зур популярлык казана. Әмма, әйтергә кирәк, галимнең һәр китабы, һәр ачышы алкышлар белән каршы алынмый. Лев Николаевич бик авыр тәнкыйть шартларында хезмәт итәргә дучар була. Танылу бәхете гомеренең соңгы көннәрендә генә елмая. Анда да төрки-татар хакында хак язган тарих өчен янаулар тукталмый.

vk.com

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Кызыклы фактлар

➢ Лев Гумилев бәрәңге ашамый, аны рус крестьяннарына килгән бәла-казаларның сәбәбе дип саный. Шуңа күрә хәләл җефете Натальяга ашка шалкан салырга туры килә.
➢ Юлга чыгарга җыенса, вокзалга бер сәгатькә алдан килә торган була, чөнки поездның иртәрәк китүеннән курка.
➢ 1966 елда Гумилев чит илдә беренче һәм соңгы тапкыр була. Ул Прагада археологлар корылтаенда катнаша.
➢ Гомеренең соңгы көннәрендә бик җитди төстә фәнни фантастика һәм детективлар белән мавыгып китә.

КҮҢЕЛ КҮЗЕ КИРӘК

Рамил абый кечкенә чагында күзлек киеп йөри. Олырак сыйныфларда укыганда исә, бер күзенең тагын начарланып китүен сизеп ала. Әмма икенче күзе әле бирешми. Шул күзе белән 25 яшенә кадәр яши ул. Әнә шуннан соң аның дөньясы караңгылана, тормышы икегә бүленә.

Дөнья яктысын күреп яшәгән егеткә дөм сукыр калу бик авыр була. Тормыштан күңеле кайта, хыяллары чәлпәрәмә килә. Ярый әле ул чакта киңәш бирүче, ярдәм кулы сузучы әти-әнисе, туганнары була.

– 1994 елда Волоколамскидагы Сукырларны тернәкләндерү үзәгенә юл тоттым. Анда бару миңа сабак булды. Үзем кебекләр белән аралашкач, мин, һич югы 25 яшемә кадәр дөньяны күрергә өлгердем бит әле, дип сөенеп куйдым. Тернәкләндерү үзәгендә дәваланучыларның барысы да тумыштан сукыр иде, – ди ул. – Шунда мин күп тапкыр шөкер иттем. Аяк-кулларымның йөрүенә сөендем. Урын өстендә ятучылар күпме бит, дип уйлана башладым. Әгәр егылып имгәнгән булсам, нишләр идем, дим. Гомере буе арбада гына утырып хәрәкәтләнүчеләр дә бар бит. Үземне шулай тынычландырдым һәм авыр уйлардан котыла алдым.

Аннан кайткач, Рамил абый Кисловодск шәһәренә китеп, медицина институтына укырга керә. Соңгы курста Ижаудан килгән Ольга исемле туташ белән таныша. Аның да күзләре начар күрә. Яшьләр бер-берсен ошаталар. Маңгай күзләре күрмәсә дә, күңелнеке алдамый бит. Хәтта яхшырак та күрә. Рамил абый яшерми: ул кызның тавышына гашыйк була. Ә кыз бу чакта бераз гына булса да күрә әле.

– Без озак йөрмәдек, өйләнештек. Бер елдан бәхетебезне түгәрәкләп, кызыбыз туды. Баштарак хатынымның әниләрендә яшәдек. Сабыйны алар үстерешә. Аннан соң минем әниләргә кайттык. Массаж ясаучы булып эшкә урнаштым, хатыным укуын дәвам иттерде. Кызыбызны әни карады, – ди Рамил абый. – Әмма күз күрми дип тормадык, ничек тә балабызны үзебез тәрбияләргә тырыштык. Иялəнәсең икән ул! Иплəп кенә тотарга да өйрәндек. Әле ул чакта хатыным тагын да начар күрә башлап, күзләре бөтенләй сукырайды. Аңа да минем ярдәмем кирәк иде. Ничек итсәк иттек, авырлыкны бергә күтәреп, тормышны ничек бар шулай кабул итә алдык.

Кызлары исә 3–4 яшендә үзе әти-әнисенә ярдәм итә башлый. Әле укый белмәсә дә, кул арасына керә, аларның күзләренә әверелә. Хәзер инде кызлары Алинәгә 22 яшь икән. Шөкер, аның күзләре сау-сәламәт. Ул инде укуын тәмамлап, үз эшен ачкан. Әти-әнисенә ярдәме тагын да зуррак хәзер. Каядыр барасы булса да, ниндидер яңалыкка өйрәнергә дә – барысын Алинә күзләре белән хәл итәләр.

– Тормышта кыенлык булды инде ул. Әлеге дә баягы күрмәүчеләр өчен уңайлыклар булмау проблемасы белән очраша идек. Күзләр күрмәгәч, баганага да килеп бәреләсең, имгәнәсең дә. Әмма тагын шул ягы бар: күз күрми башлагач, колак ишетү, ис сизү, тоемлау көчәйде. Стена яки ишекнең кайда икәнен, янымда машина торуын сизәм. Тормыш үзе өйрәтә икән ул. Яшәү теләгең булса, барысына да өйрәнәсең. Минем әниемә – 80 яшь. Ул бер дә зарланганымны яратмый. «Аллаһы Тәгаләнең ачуын китермә», – дип кенә тора.

Мостафиннар күрмәүчеләргә ярдәм итәргә өйрәтелгән эт тә алганнар. Аларда яши башлаганына 6 ел икән.

nurlat-tat.ru

– Шушы эткә мең рәхмәт инде. Ул безне йөртеп тора. Эт белән күргәч, кайчак безне сүгеп тә ташлыйлар. Тешләр, диләрдер инде. Әмма безнең кебекләр өчен өйрәтелгән этләр кешегә тими, – ди Рамил абый. – Беләсезме, сеңлем, мин үземне начар күрүчеләргә яки аның этенә кисәтү ясаучы күп кенә сау-сәламәт кешеләрдән бәхетлерәк дип саныйм. Моңаеп, кимсенеп утыру бөтенләй хас түгел миңа. Адым саен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтерлек бит тормышым. Торыр җирем бар. Янымда хатыным, кызым буй җитте. Күңел күзем яхшы күрә. Һәркемнең уен сизәм, ни әйтергә теләгәненә кадәр тоям мин!

СИРИНӘНЕҢ ӨЧ ХЫЯЛЫ

Гөлия Фаизова

Казанда яшәүче Сиринә Хәсәновага табиблар тугач та ДЦП диагнозы куя. Хәзер аңа – 32 яшь. Шөкер, куллары хәрәкәтләнә, бөтен эшне үзе башкара ала. Тик менә аяклары гына тыңламый. Ә Сиринәнең бик тә аягына басасы килә.

– Әнием Миләүшә авырлы вакытта караңгыда адашып, сазлыкка килеп керә. Шунда чактан гына үлемнән котылып кала. Саз аны үзенә суыра башлый. Үзе сөйләгәнчә, 9 айлык көмәне генә бөтенләйдән батудан саклап кала. Ярдәм килгәндә, ул бик хәлсезләнгән була инде, – дип искә ала Сиринә. – Ул чакта мин әнинең эчендә бик каты тибенгәнмен дә кинәт туктап калганмын. Табиблар, бу балаңнан котыл, дисәләр дә, әни табарга дип карар кылган. Көтеп алган беренче сабыйлары бит. Туганда ук аякларым хәрәкәтсез була. Табиблар аптырагач, әнә белән чәнчеп тә карый. Тик мин аны тоймаганмын. Диагноз кирәк булгач, ДЦП дигәннәрдер инде.

Сиринә туып бер ел да үтми, энесе дөньяга килә. Гаиләнең тормышы түгәрәкләнеп китә. Ике бала бергә үсәләр. Сиринәнең дә, энесе кебек, урамдагы балалар белән чабып йөрисе, бергә уйныйсы килә.

– Үз аягымда йөрергә гомерем буе хыялландым. Йөреп китәсемә әле дә ышанам. Аллага шөкер, туган авылымда урта белем алдым. Укытучыларым өйгә килеп укыта иде. Мин аларга бик рәхмәтлемен. Мәктәпне тәмамлагач, бухгалтерлыкка укып чыктым. Психолог булырга да укыйм әле мин. Тик утырганым юк. Аллаһы Тәгалә миңа иң зур бүләк ясады. Мин үз бәхетемне таптым. Кияүгә чыгып, бала таптым, – ди Сиринә.

Кыз социаль челтәрләрдә дуслар таба. Егетләр белән дә аралаша. Беркайчан да үзенең йөри алмаганын яшерми. Дөрес, бу хакта белгәч, араны өзгән егетләр дә була. Ә менә Марат Сиринәне бер күрүдә яратып, язмышын аның белән бәйләгән.

– Хатын-кызның бар бәхете кияүгә чыгып, бала үстерүдә дип уйлыйм. Әнә шуңа да кияүгә чыгу теләгем зур иде. Без Марат белән декабрь аенда социаль челтәрләрдә язышa башладык, февральдә ул мине күрергә килде. Май аенда әтиәниләр таныштык. Июльдә без никах укыттык, – дип искә ала Сиринә. – Иремнең әти-әнисенә дә рәхмәтлемен. Берәүнең дә баласын арбада утырган кызга өйләндерәсе килмидер инде ул. Ә алар Маратка каршы килмәделәр.

Яшьләр гаилә корып җибәреп, бер ел дигәндә, уллары Альяс дөньяга аваз сала. Сиринә бала көткән вакытларын сагынып искә ала.

– Авырлы икәнемне белгәч, бик шатландым. Сабыемны җиңел күтәрдем. Райондагы табиблар баштарак куркыткан иде. Әмма Казанныкылардан җылы, матур сүзләр ишетүдән, мине башка саусәламәт хатын-кыз кебек итеп кабул итүләреннән күңелем күтәрелде. Ә инде улым тугач, бар дөньям түгәрәкләнде. Сабыемны кесарь кисеме белән алдылар. Аның беренче тапкыр елап җибәргәне колагымда әле дә ишетелә, – ди ул.

Язмыш дими, ни дисең: Чүпрәледән Казанга бәби табарга дип киләләр дә шунда төпләнеп кала алар. Әлегә кеше фатирында яшәсәләр дә, бер дә зарланмыйлар. Ирем, улым белән кайда да рәхәт, ди Сиринә. Ирле тормышына әле дә сөенеп туя алмый. Мараты бәби карашырга гына түгел, бөтен эштә ярдәм итә икән.

– Яшәүнең мәгънәсе артты. Беләсезме, безнең хәтта үпкәләшкән, ачуланышканыбыз да юк. Гомерне әрәмгә уздырасы килми. Бер-беребезне хөрмәт итеп яшәргә тырышабыз. Улыбыз да тыныч бала булды. Ашый, уйный, йоклый. Шушы көннәрдә бер яшь тә 5 ай булды үзенә, – ди Сиринә. – Минем хыялларым бик күп. Гаиләм белән бергә чит илгә барасым килә, кыз бала сөясем килә. Аягыма басарга да уйлыйм бит әле мин. Кайнар чәй түгелсә дә, салкын булса да сизәм. Тоялар икән, димәк, алар йөри дә алачак. Күңелем белән бу хыялларның тормышка ашасына ышанам. Аллаһы Тәгалә безгә гел ярдәмен биреп тора. Бу юлы да ташламас әле.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ФАКИЛ САФИН: «ЫШАНМЫЙЧА, КАЯ БАРЫЙК?..»

Читтән яхшырак күренә. Фикер белешкәндә, без әнә шулай дияргә яратабыз. Бу юлы хәл-әхвәлебез, әдәбият проблемалары хакында Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге рәисе, Тукай бүләге иясе Факил САФИН белән сөйләштек.

:: Факил абый, Чаллы язучылары көчлерәк, бердәмрәк, оешканрак, диләр. Аның сәбәбе нәрсәдә?

– Болар – хак сүзләр. Тик бераз төзәтмә кертик, «Чаллы язучысы» дигәнне «Чаллыда яшәүче язучылар» дип үзгәртик. «Чаллы язучысы» дисәк, безне гомум татар әдәбиятыннан, әдәби процесстан аерып куйган кебек була. Без көчлерәк, чөнки язучыларыбызның күбесе – тормыш сынауларын үткән кешеләр. Казаннан читкә киткән саен, үз төбәкләрендәге иҗат кешеләренең бер-берсенә тартылуы – табигый хәл. Җитмешенче елларда Чаллыга килеп төпләнгән язучыларның күбесе Казанга «сыеша» алмаган каләм әһелләре иде. Бунтарьлык, дуамаллык, башбирмәүчәнлек, бер-берсенә юл куймау – болар барысы да бар иде. Шул ук вакытта алар бер-берсеннән башка яши дә алмыйлар кебек иде. Соңрак килгән каләм ияләрендә бу гадәтләр юк, дияргә була. Сиксәненче елларда, туксанынчы еллар башында белемле, төпле, талантлы кешеләр шактый җыелды бу шәһәргә. Бүген дә бүлекнең йөзен алар билгели. Безнең буын, беренче чиратта, гаилә хәлләрен истә тотып, Чаллыда төпләнеп калды. Фатир, эш мәсьәләләре автогигантта тизрәк хәл ителә иде. Шуңа күрә берара Казаннан Чаллыга килеп, Рәис Беляев җитәкләгән партиянең шәһәр комитеты аша фатир алып, алган фатирларын кабат Казанга алыштырып китүчеләр булды. Кайберләре Чаллы оешмасын җитәкләгән дә икән әле. Сораштырганым бар, аларның «җитәкчелек» иткән вакытларын җүнле-башлы белгән кеше дә юк. Без бердәмрәк, аңлашыла – шулай булганда гына уңышларга ирешә алабыз. Без һәр каләм иясенең иҗатына игътибарлы, беркемне дә читкә какмыйбыз. Шулай булганда гына иҗат учагының дөрләп торачагын күпләр белә. Без оешканрак, чөнки бер шәһәрдә яшибез, бергә җыелу, сөйләшү-фикерләшү өчен мөмкинлекләр дә, тема да җитәрлек. Мичурин бабай әйтмешли, без табигатьтән рәхимлек көтеп тора алмыйбыз. Үзебезгә туктаусыз хәрәкәт итәргә, эзләнергә, табарга, тапканны матур итеп башкаларга күрсәтә белергә кирәк.

> Соңгы еллардагы пандемия зәхмәте генә кызуны бераз сүрелдерде кебек. Язучыларыбызның юбилейларын иң шәп залларда, зур кунаклар чакырып үткәрү гадәткә керде. Яңа китап чыкса, шунда ук тәкъдим итү кичәләре үткәрәбез. Төрледән-төрле очрашуларның исәбе-хисабы юк. Гомумән алганда, бер-беребезнең иҗат уңышларына сөенәбез, хәл-әхвәлләрен белешеп торабыз. Үзем язучыларның балаларын гына түгел, оныкларының исемнәренә кадәр беләм. Очрашкач, һәркайсы турында ныклап сорашмыйча калмыйм.

:: Көчле язучылар белән идарә итү дә авырдыр?

– Әгәр дә кемдер язучылар белән идарә итеп була дип уйласа, бик нык ялгыша. Кырык еллап гомерем тэге яки бу дәрәҗәдә җитәкче булып үтте. Бер генә вазыйфада да, беркем белән дә идарә итү турында уйлап та карамадым. Кеше нәрсәгә сәләтле? Талант чамасы ничек? Башта шуны күзәтәм, аннан кешенең мөмкинлекләрен үстерү ягын кайгыртам. Шуннан соң инде булган мөмкинлекләрен эшчәнлекнең төп юнәлешенә борырга омтылам. Күп очракта бу барып чыга. Җитәкче буларак, Чаллыда әдәби мохитне югары дәрәҗәдә тотарга тырышам. Мохит ул – каләм ияләренең аралашуы, үзара әңгәмә барышында фикерләре чарлана, әдәбияттагы, тормыштагы тегe яки бу вакыйгаларга карашлары ачыклана, бәхәсләр дә булып ала, еш кына ни дә булса язарга дәрт тә уяна. Нәкъ менә әдәби мохитнең дөнья әдәбиятында гаҗәеп әсәрләр язарга сәбәпче булганлыгын да беләбез бит. Мохит ул иҗат белән генә чикләнми, эш-хезмәт урынындагы мохит, дөньяви мохит, гаилә мохите, хәтта үз-үзеңдә барлыкка килә торган виртуаль мохит тә иҗатка йогынты ясый. Кайбер каләмдәшләр: «Миңа бернинди мохитнең кирәге юк», – дип тә җибәрә. Бусы инде – аларның фикере. Бәхәсләшмим. Кеше ниндидер уңышларга ирешсә, нигилизмга авыша башлый бит.

:: Казаннан читтә яшәүче язучыларга игътибар җитәрлекме?

– Безнең Татарстан Язучылар берлегендә ике бүлек эшләп килә – Әлмәт һәм Чаллы бүлекләре. Әлеге бүлекләрдә исәптә торган каләм ияләренең иҗатларын күрсәтү, таныту, үзләрен төрле әдәби премияләр белән бүләкләү һәм башка якларны шактый кайгыртабыз. Билгеле, бу эштә Язучылар берлеге идарәсенең бик тә объектив һәм киң күңелле булуы кирәк. Әмма Әлмәт һәм Чаллы бүлеге җитәкчеләре буларак, идарәгә кергән ике кеше көче белән генә Казаннан сайланган егерме биш кешенең башка төбәкләрдәге иҗатташларына да хәерхаһлы булуларына ирешеп бетеп булмый шул. Безне сирәк «ишетәләр». Үткән көз Түбән Камада яшәп иҗат итүче юмор һәм сатира әсәрләре язып танылган Илдар Хәйруллинга Гамил Афзал исемендәге премияне бирү мәсьәләсен күтәреп чыккан идем (Гамил Афзал премиясе башлыча юмор-сатира өлкәсендә эшләүче иҗат әһелләренә бирелә. – **Ред.**). Урын өстендә яткан килеш ничә китап чыгарды ул! Диңгезче, гаярь егет иде! Дистә еллар дәвамында иҗади батырлык үрнәге күрсәтте Илдар безгә. Гамил Афзалча инде: «Үзем үлеп ятам, үзем көлеп ятам», – дия иде, шаяртып. Әсәрләре нинди генә сәхнәләрдән яңгырамады. Чыгыш ясадым, әмма мине идарәнең бер генә әгъзасы да яклап чыкмады. Премиягә башка кешене тәкъдим итүне хуп күргәннәр. Шушы көннәрдә генә Илдарыбыз бакыйлыкка күчте… Казаннан сайланган идарә әгъзалары безнең каршыда «кәттәләнергә» яраталар. Моны яшереп торасы юк. Ә бит шактый язучылар Татарстаннан читтә, алар аерым бүлекләрдә дә тормыйлар. Аларны кайгыртучы да юк дияргә була, сирәк очракларны искә алмаганда.

:: Чаллы – яшьләр шәһәре, дип әйтәбез. Яшьләр күңеленә ачкыч ничек ятарырга, туган телләреннән бизмәсеннәр өчен нәрсәләр эшләргә?

– Иң катлаулы сорау. Җавап бик гади – туган телгә ихтыяҗ булса, тел яши, димәк, яшьләр дә татарча укыйлар, арада иҗатка тартылучы талантлы яшьләр дә булачак дигән сүз. Әмма бусы – соңгы елларда еш яңгырый торган буш сүзләр тезмәсе генә.

nkamsk-rt.ru

Милли мәгариф тәмам тар-мар ителде, барлык фәннәрне тулысынча татарча укыта торган татар мәктәпләре бетте, дияргә була, югары уку йортларында татар телендә белем алудан мәхрүм калдык. Инде бүген үк татар теленең язмышы кызганыч хәлдә. Атнага бер сәгать тел, бер сәгать әдәбият укытып кына ерак китеп булмас. Өстәгеләр гаиләгә төртеп күрсәтә, гаилә өстәгеләрдән нидер көтә. Татар телен өйрәнү БДИ нәтиҗәләренә йогынты ясамый икән, аны кем укысын? Сафсата сатып эш пешми. Хәзерге чор яшьләре дөньяның кай якка барганын яхшы аңлый һәм гаҗәеп рациональ фикер йөртәләр. Ата-аналарда исә конформистик карашлар өстенлек итә.

Туксанынчы еллар башында Чаллыда берничә мәктәптә иҗат түгәрәкләре оештырган идем. Балалар, пыр тузып, шигырь язалар, әкиятләр уйлап чыгаралар. Ә бастырырга урын юк, бердәнбер «Яшь ленинчы» газетасы редакциясенә керсәң, хезмәткәрләрнең өстәлендә тау-тау кулъязмалар өелеп ята. Балалар исә язмаларының газета битләрендә басылып чыгуын көтә. Үзем аларны шулай дәртләндереп торам. Хәлне аңлап алгач, Чаллыда балалар һәм яшүсмерләр өчен аерым газета чыгару артыннан йөри башладым. Каршылыклар күп булды, иң беренче үзебезнең татарлар, милләтпәрвәр саналып йөрүчеләр аяк чалып маташтылар. Биреләргә ярамый иде, газета оешты, бүгенге көнгәчә уңышлы чыгып килә. Без газетаның беренче редакторы Нәсимә Садыйкованы һәрвакыт зур хөрмәт белән искә алабыз. Чөнки кайберәүләр мине баш мөхәррир итеп куйдыртмас өчен көрәшеп йөргәндә, шәһәр җитәкчеләре белән сөйләшеп, Нәсимә ханымның ризалыгын алып, аны баш мөхәррир итеп раслатырга өлгердем. Бүген әдәбиятка, сәнгатькә килгән яшьләребезнең күбесе «Көмеш кыңгырау»ны укып, үзләре язышып үстеләр. Яшьләр туган телгә, милли проблемаларга битараф түгел. Үзләренчә нидер уйлап чыгаралар, клублар, төркемнәр оештыралар. Шунысы бар: яшьләр өлкәннәр ягына карамый, өлкәннәр яшьләр белән кызыксынмый диярлек. Буыннар арасында упкын барлыкка килеп маташа, моңа игътибар итәргә ашыкмыйбыз.

:: Матбугат турында сүз чыккач, «Мәйдан» журналы язмышына да тукталыйк. Чагыштырмача яшь, сезнең көч белән оешкан бу басма төрлесен кичкәндер, «Аргамак» кебек көчле журналның дәвамчысы да булырга кирәк бит әле. Бүген ул ни хәлдә?

– «Мәйдан» журналын «Аргамак»ның дәвамчысы дип, вазгыятьне белмәгән кешеләр генә сүз йөртә. 20 ел элек «Мәйдан» журналы, оешканда ук аерым басма булып, башка юнәлешне күздә тотып оешты. Ул вакытта, кызганыч, «Аргамак» күтәрәмгә калып, ике мәртәбә ликвидация процедурасын үтеп (гаҗәп хәл: бер журнал теркәлгән ике Устав белән яшәп яткан. Ике Устав – икеләтә салым. Редакция исә салымнарны еллар буена түләргә бөтенләй «оныткан»), бетеп ята иде инде. Моның калган сәбәпләрен, сәбәпчеләрен әйтеп тормыйм. Мине, журнал оештыру өчен, Казаннан, «Казан утлары» журналында әйбәт кенә эшләп йөргән җирдән чакырып кайтардылар. Чаллының ул вакыттагы хакиме Рәшит Хәмәдиевнең инициативасы белән оешты ул. Гамәлгә куючылар шәһәр хакимияте һәм Татарстан Язучылар берлеге булды. Беренче сөйләшүдә үк берлек рәисе Фоат ага Галимуллин шәһәр хакименең яңа журнал чыгару турындагы фикерен тыңлагач: «Мин, берлек рәисе буларак, журналның баш мөхәррире Факил Сафин булса гына, гамәлгә куярга ризалык бирәм», – дип кистереп әйтте. Рәшит Сәет улы, дәртләнеп китеп: «Баш мөхәррир Факил Сафин булса гына, журналны финанслыйм!» – дип белдерде. Ул сөйләшүдә катнашкан кешеләр исән. Башка вариант юк иде, журнал оештыру эшенә тотындым. Җиңел булмады, беренче саннары дөнья күрүгә, шул ук каршы көчләр, каршы эш мәтәштереп, шактый кыенлыклар тудырдылар. Әле соңгы елларда да журналны ябарга тырышулар булды. Шәһәрнең бүгенге хакиме Наил Мәһдиевкә рәхмәт, минем мөрәҗәгатьне кабул итеп, журналны яклап чыкмаса, бүген инде «Мәйдан»ның язмышы ничек булыр иде?.. Бүген дә, шөкер, журнал чыга, әмма тагын бер «акыл иясе» табылып, журналга ябырылмас дип әйтә алмыйм…

:: Татар язучысына китабын үз татары укысын өчен дә шактый тырышырга кирәк. Аның артында агентлыклар, үзәкләр, зур нәшриятлар тормый. Бу очракта әсәрне популярлаштыруның нинди юлларын табарга?

– Татарлар сигез миллион, дип мактансак та, аның миллион чамасы гына татарча укый белә. Агентлыклар, үзәкләр булсын өчен, ким дигәндә татар телендә теттереп сөйләшә торган ун-унбиш миллион татар булырга тиеш. Бусы – төп мәсьәлә. Инде килеп, әгәр язучының китабы Татарстан китап нәшриятында чыга икән, таратуда зур проблема күрмим. Китапларның сиксән биш проценты Милли китапханә аша республикага һәм Татар конгрессы аша башка төбәкләргә тарала. Президентыбызның әлеге карары, шиксез, үтәләдер, дип уйлыйм. Кызганыч, нәшрият чыгарган китаплар мәктәп китапханәләренә генә барып җитми. Соңгы елларда

көнкүреш романнары язучы каләм ияләре барлыкка килде. Алар үз китапларын район-шәһәр китапханәләрендә үткән очрашуларда шактый уңышлы саталар. Китапны бизнес чыганагына әйләндерә алган авторлар килеп чыкты. Моны гаеп эш итеп күрмим. Күп авторлар китапларын чыгаралар да бушка таныш-белешләренә өләшеп йөриләр. Алар күпчелек. Китап сату өчен дә осталык кирәк.

Чаллыда яшәүче язучылар укучылар белән очрашуларда еш булалар. Автор белән очрашкач, китапның эчтәлеге белән танышкач, сатып алырга теләүчеләр яки китапханәләрдән шул китапларны сораучылар күбәя. Моны эш практикамнан чыгып әйтәм. Авторлар ешрак үз укучылары янында булсыннар иде. Тик күп язучыларның андый мөмкинлеге юкмы, теләкләре җитмиме, барысы да укучылар белән очрашуга атлыгып тормыйлар. Укучыларны үзләренә җәлеп итәрлек каләм ияләре бармак белән генә санарлык. Яшермим, әдәбиятка ялгышыпмы, адашыпмы килеп кергән, бөтенләй язучылык таланты булмаган графоманнар да (бу урында «графоман» сүзе дә күп аларга) бар бит. Алар әле талантлы язучыларга караганда өлгеррәк тә, әрсезрәк тә...

Әсәрләрне популярлаштыруның юллары күп төрле, телевидение, радио («Китап» радиосы оешу үзе генә дә ни тора!), газета-журналларда рецензияләр, җәһәт бәяләмәләр, тәкъдим итү кичәләре... Һәркайсы – файдага эшли торган чаралар. Шөкер, безнең республикада әле моңа мөмкинлекләр бар. Иң мөһиме – яхшы әсәр язу. Тозсызны күзсез дә сизә. Булыр-булмас әсәрне күпме югары чөймә, беркөнне барыбер җиргә егылып төшәчәк.

:: «Саташып аткан таң» – үткәннәрдән сабак алырга өндәгән фаҗигале язмышларны бәян иткән роман. Документаль әсәр дип әйтеп буламы?

– Әлеге романны язарга физик, рухи һәм психологик яктан әзерләнеп беттем дигәч тә, каләм алырга җөрьәт итмичәрәк тордым. Шунда Туфан ага Миңнуллинның бер язмасын укыдым. Анда халык язмышы турында сүз бара иде. Туфан ага болай дип искәрткән: «Бәлки, аны искергән тема дип уйлаучылар булыр. Халык язмышында фаҗига искерми. Үткәннәрне искә төшереп, без киләчәкне кисәтеп куябыз». Шушы сүзләрне укыгач, барлык шик-шөбһәләр юкка чыкты, дәртләнеп, эшкә тотындым. Юнәлеш билгеле, максат ачык булса, әсәр тиз языла. Әсәр документаль нигездә иҗат ителде, чөнки төп герой – конкрет шәхес, Әхмәтсафа Дәүләтьяров. Репрессия корбаны. Күп йөрергә, дистәләгән кешеләр белән очрашырга насыйп булды, хәтта төп геройның туганнары ярдәмендә, КГБ архивында да эшләп алдым, әмма автор фантазиясенә урын күп бирелде. Әсәрнең укылышлы булуын тәэмин итү өчен дә, аны әдәби югарылыкта тоту өчен дә шулай кирәк иде.

:: Балалар әдәбиятына кайтсак, сезнеңчә, ул нинди хәлдә? Шәүкәт абый Галиевләр заманындагы кебек геройлы (Шәвәли, Мәсәлән) әсәрләр бармы? Үсмерләр кызыгып укырлык хикәя, повесть, романнар бармы?

– Заман башка, вазгыять башка. Шәүкәт абый бүгенге хәлләрне күрсә, йөрәге тотып авар иде. Шәвәли – ихлас, самими, беркатлырак, шук, һәрнәрсә белән кызыксынучы татар малае образы. Ул чакта балалар (безнең буынны да кертеп) әдәби китапларны егылып укый иде. Әдәбият дөньяны танып белүдә үзәктә тора иде. Сибгат Хәким сүзләрен искә төшерик: «Һәр яңа аваз серле!» Сернең төбенә төшәргә омтылу күңелне җәлеп итә, яшәешкә кызыксыну уята. Хәзерге әдәбияттан балалар ниндирәк сер ала соң? Яңа технологияләрнең тормышка үтеп керүе балаларның дөньяны кабул итү мөмкинлеген, дәрәҗәсен дә үзгәртте. Алар хәзер башка. Шикәрен суга салган Шәвәлигә алар борылып та карамый. Аларның, гомумән, бер генә әдәби персонажга да исләре китми. Әле мәктәпләрдә бераз татарча укучы балалар бар, алар белән еш очрашып торам, матур итеп, сәнгатьле, образлы итеп язган әсәрләр ошый аларга. Әсәрнең яңгырашына игътибар итәләр, телнең аһәңен тоялар, моңын искәрәләр. Шушы үзенчәлекләр эчтәлек белән бербөтен тәшкил итсә, алар кызыксынып тыңлыйлар, очрашу беткәч, урап алалар. Күзләрендә яктылык, йөзләрендә нур күреп, күңелем тула. Шулай ук балалар тормыштан алынган реаль геройларны тасвир кылган әсәрләрне үз итәләр. Бармактан суырып, а-ля Гарри Поттеризм, шаккатыризм тибындагы әсәрләр җаннарына милли рух чаткылары сибелгән татар укучысы рухына туры килми. Авторлар язмыйлар түгел, тырышып карыйлар бит инде, яңа әдәби геройлар да тәкъдим итүчеләр булгалый. Бәхетсезлек дими ни дисең, ни генә кылан, балалар аларны без теләгәнчә кабул итми. Татарча аңлаган балалар (шулай аерып әйтергә туры килә инде) гомуми кыйммәтләрне алга куеп язылган югары зәвыклы әсәрләрне рәхәтләнеп тыңлыйлар да, укыйлар да. Тик монда да өлкәннәр башка якка каера. Шуңа барып җиттек: «гомумкешелек кыйммәтләре» дигән төшенчәләрне кире кагучылар табылды. Беткәч, бетик әйдә, ди торганнардыр инде. Татар әдәбиятын гына түгел, гомумән, әдәби әсәрләрне егылып укучылар бик аз, элек без алтынчы-җиденче сыйныфларда укыганда, бусы – өлкәннәр өчен, бусы – балалар өчен, дип, аерып тормый идек.

> Халык арасында «шәп әсәр» дигән даны таралса, ничек итсәк итә идек, ул китапны барыбер табып алып укый идек. Калын романнарны укып чыгу берни тормый иде. Хәзер алай түгел инде. Яшүсмер чагым китап белән үтте. Дөньяга карашның ныклы нигезе яшүсмер чакта формалаша бит. Элек бала рухына тәэсир итүдә әдәбиятның роле зур булса, хәзер виртуаль дөньяда ярала балаларның фикер үсеше. Ә анда караңгылык хөкем сөрә кебек тоела миңа. Аларны бу якты дөньяга ничек алып чыгарга? Менә кайда мәсьәлә...

:: Нинди генә проблема туса да, гадәттә без «Ә нишләп язучылар үз сүзләрен әйтми, ә нишләп язучылар мәйданнарга чыкмый?» дигән сорау бирәбез. Җәмгыятьнең бөтен проблемаларын язучыларга гына аударып калдыру дөресме соң?

– Язучылар проблемаларны читләтеп үтмиләр, һәрчак үз сүзләрен әйтеп киләләр. Сорауга каршы сорау: халкы мәйданга чыгарга курыккан язучы, күтәрелеп, мәйданга чыгып басар микән? Мәйданнарга чыгып, соңыннан хөкем юлларында йөргән язучыларыбызны халык, яклап, бер каләмә сүз әйттеме? Милли узаң диләр, баксаң, бездә ул бик зәгыйфь икән бит. Татар бүген, гариза язып, туган теленнән ваз кичә. Шундый хәлдә без. Язучыларыбыз туктап тормыйлар, һаман язалар, төрледән-төрле проблемалар күтәрәләр, ул проблемаларның чишелеш юллары да күрсәткән булалар, талантлы әсәрләре белән татарның Җир йөзендә яшәргә хаклы икәнен раслыйлар. Киләчәккә ышана инде алар, бахыркайларым...

:: Укучыга әйтер сүзегез?

– «Ватаным Татарстан» газетасы укучыларына бәхетле, туган телле гомер телим.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

РҮЗӘЛ МӨХӘММӘТШИН

МИН ДӘ ҮЛӘРМЕН ӘЛЕ...

(ХИКӘЯ)

< Ахыры. Башы 26 август, 2 сентябрь саннарында

Бераздан Ройканы кабергә төшерделәр. Минем сулыш ешайды. Йөрәк, чыгып китәрдәй тибеп, канны кызурак куарга тотынды. Хәл китте, баш әйләнде.

Ройка ап-ак кәфенлектә кып-кызыл туфрак эчендә ята иде...

Аны бу хәлдә күреп бөтенләй бетәштем.

Ярабби!

Минем күз алдымда ләхетне томаларга керештеләр. Иң элек аякларын капладылар, аннары – гәүдәсен, башын... Ройка бушлыкта, караңгылыкта һәм... куркыныч ялгызлыкта (караңгыдагы коточкыч куркыныч ялгызлыкта!) калды. Мин, җилдә атынган тере карачкыдай, ул-буны аңламый торганда, кабер өстенә туфрак ишелә башлады, элгәре бер учбер уч кына ташлаган авылдашлар отыры көрәккә үрелде... Һәм Ройка бөтенләй юкка чыкты.

Ни кичерә икән ул хәзер?

Ничек икән ул – үле килеш анда, беркемнең буе җитә алмаслык аста, юештә, салкында ялгызы яту?

Һәр иртә саен кояш туачак. Таң атачак – кич җитәчәк. Ә син юк. Барысы да бар, барысы да үз урынында: чәчәкләр, таулар, агачлар, елгалар, йортлар, шәһәрләр, дөнья!

Ә син юк...

Һәр көн саен кешеләр каядыр ашыгачак, кемнәрдер талашачак, сөешәчәк, балалар тәпи йөрергә өйрәнәчәк...

Җиһан, һәр көз саен алтынсу төскә һәм пычракка батып, һәр кыш саен аклыкка, сөт кебек, аклыкның үзе кебек ап-аклыкка күмеләчәк.

Һәр яз саен бөреләр шытып, анадан тума каен кызлары, читенсенеп кенә, киемгә төренәчәк, елгалар ташып агачак.

Ә син юк...

Дөнья шулкадәр матур һәм бәхеткә тиенер өчен сиңа бик аз, бик аз нәрсә – бары тик... булу, исән булу, яшәү җитәр иде!

Әмма син юк.

Барысы бар, барысы үз урынында!

Ә син юк.

Һәм, бәлки, иң куркынычы: син генә юк!..

Сәдака өләшеп чыктылар. Мулла тагын бер кат дога кылганнан соң без, зираттагылар, төркем-төркем авылга таба кузгалдык. Кемдер тәмәке кабызды. Җирәнгеч татлы ис борынны кытыклап, күзләрне яшьләндерде. Шулкадәр табигый, шулкадәр саф һәм гөнаһсыз тәмәке төтене...

Ройка тартуын ташлыйсы килеп йөргән иде...

Өлгердеме икән?

Кыш азаклары, имеш. Бәлки, яз башы.

Киң басу. Тоташ аклык. Җиңелчә буран себерә. Без җәүләнә каядыр барабыз. Юл юк. Әмма йомшак кар өстеннән шулкадәр җиңел, рәхәт үтелә. Аяк асты убылмый да, батмыйбыз да.

Бераздан Ройка кырыйга салулый башлады. Мин икеләнә калдым. Уңны-сулны барлар өчен адымымны сирәгәйттем.

– Син дөрес якка бармыйсың! – дип әйтәсем килде.

Әмма үзем:

– Шулай да, ни өчен төшләремә керәсең син? – дидем.

Ул да баскан җирендә тукталды. Җилкәсе аша гына карап, җавап бирде:

– Чөнки... син...

Җөмлә азагын җил йотты. Ишетеп өлгермәдем. Ә ул әйтте югыйсә. Әйтте дә уңга – кояш баешына китте.

Мин сулга – кояш чыгышына борылдым.

Сискәнеп, күземне ачтым. Торып утырдым.

Йөрәк янә урыныннан купкан иде: дөп-дөп, дөп-дөп...

Без дуслар идек.

Бергә трай типтек, бергә төрле эшкә йөрдек.

Мотоцикллар ярата иде ул. Кара күзлекләр, күн курткалар, пистолетлар... Кыскасы, кырку егет булырга ярата иде.

Бик матур рәсемнәр ясый иде. Бер рәсеме миндә әле дә саклана...

Сөеклесен дә, әлбәттә, ярата иде. Бик нык – мотоцикллар, пистолетлар яраткан кебек. Кырку булырга яраткан кебек.

– Туй чамаланса, шаһит эзләп тормам инде? – дип салды берсендә.

Мин шатланып ризалаштым:

– Әлбәттә.

Язмаган, нишләтәсең.

Шөн Сабан туенда без бергәләп мәрхүм яшьләрне, яшьтәшләрне искә алып утырдык. Кайсы асылынды. Кайсы һәлакәткә тарыды.

Мин шулвакыт:

– Яшисе дә яшисе иде бит әле аларга! – дип уфтандым.

Ройка, тирән сулыш алып:

– И Аллаһ, – дип, сүземне җөпли торды.

И Аллаһ!..

Яшисе дә яшисе иде бит әле Ройкага да!

Рәхәтләнеп яшисе дә яшисе иде!..

Ул арада Рауза карчык Аллаһка әйтергә теләгәнен әйтеп бетерде. Битен сыпырды. Борылып, иңемә кагылды.

Әни җибәргәнгә генә килдем мин. Дога сорыйдыр, бар, юкка төшеңә кермәс, дип көндерде. Аның фикеренчә, берничә тәңкәлек сәдака Ройканың хәлен (һәм шулай ук минекен дә) шактый җиңеләйтергә тиеш иде.

Догачыга рәхмәт әйтеп, урамга чыктым. Кич бүген дә аяз иде – һәрбер йолдыз аермачык күренеп тора. Буең җитсә, Рауза карчыкның таягы белән бер-икесен бәреп төшерергә дә мөмкин әле. Түбән очка атладым. Менә бер йортны уздым, менә икенчесен. Менә Ройка яшәгән йорт турына җиттем. Ройканың бүлмәсендә ут яна иде...

Ул көнне шулкадәр изрәп, шулкадәр рәхәтләнеп йокладым мин.

Бернинди төш кермәде.

2011

ЧИКЛӘВЕК ҖЫЯБЫЗ

Хак лайфхак!

- Урманга барганда ачык җирләрегез калмасын. Бу урман бетеннән саклану өчен дә, аяк-кулларны сыдырмау өчен дә кирәк.
- Озын балтырлы бутый кию яхшы, елан килеп чыкмасын!
- Муенга асыла торган букча табыгыз. Ике кулыгыз буш булыр.

Күзлек кисәгез, күзегезгә ботаклардан чүп коелмас. Чикләвек җыйганда гел өскә карап йөрелә.

- Букчагызга карга борыны (плоскогубцы) салыгыз. Чикләвекне җыйганда аның төшен ашап карыйсы килә.
- Сирәк үскән чикләвеккә алданмагыз. Куәле куакны табыгыз. Иң өстәге бердәнбер чикләвеккә күп вакыт сарыф итү мәгънәсез.
- Эре чикләвекле куак табарга тырышыгыз. Бер куакның чикләвекләре бер үк зурлыкта була.
- Ботакларын күтәреп карагыз яки шулар астына кереп җыегыз. Чикләвек шунда яшеренә.
- Куакка кояш ягыннан килегез. Күзегез дә чагылмас, чикләвек тә качмас.
- Куак бик сыгылмалы. Озын ботакларны бер кеше аударып, икенче кеше җыю уңайлы.
- Зур ботакларны сыгу өчен озын саплы ыргак кулланырга була.
- Өлгергән чикләвек коелырга тора. Ботакларны җайлап кына, калтыратмыйча аударыгыз.
- Нык өлгергәннәрен куакны селкетеп җыярга була. Төбенә җәймә куясыз да, чикләвек шунда коела.
- Чикләвекне өйгә алып кайткач, аның өстенә йөк бастырып куярлар. Чикләвекне кишәнкесеннән куптару җиңелрәк булыр.

Әз-мәз мәзәк

* * *

Кичә кибеттә «Бөтен проблемаларның яртысын ничек хәл итәргә?» дигән китап күрдем. Икене алдым әле.

* * *

Полиция беркетмәсеннән:
«Вәлиев исерек хәлдә башын М7 трассасының 818 нче километрында бәрде».

* * *

Пакетларны пакет эчендә саклау – искелек калдыгы. Хәзер, беләсегез килсә, иске пакетларны контейнерда саклыйлар!

* * *

Буйдак һәр иртә зур сайлау алдында тора: нәрсә киярга, юылмаганнымы, әллә үтүкләнмәгәннеме?

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Әни, Әлфис, Фән, Илюшин, рия, бас, Имәни, ана, Әлбәдән, Ясминә, Неру, Галилео, сарафан, Гали, Гата, азык, учак, Гайфи, Фа, Балкан, сайра, Ола, оят, Баку, Вакыт, Вилли, кокос, ара, Рамазан, Азалия.

Вертикаль: Миңнегулов, ач, Ла, Сәер, тарак, усак, чия, бот, Фәнис, Строгая, Сара, зам, алты, Ра, әфьюн, ни, фейк, КамАЗ, банка, Фабио, Әсфира, Наина, Кызыл, Әнисә, Кто, ИНН, агымсу, Сания, ябалак, ил, Әйди, Иделия, Фаил, янкорма.



Тыелган «допинг»
Ш.Хәсәенов «... килде»
Салым түләүче номеры
Сәясәтче Виктор ...
... Вәлиәхмәтов
Татар халык җыры
Язучы ... Ярулин
Кеше күрсенгә
Габдерәхим Утыз ...
З.Хәким «... кыз» драмасы
Урыйбасар
Атаның хатыны
Әлипәгә боерык
Кош та, кар да
Пристрой
Компотны ябабыз
Хатын-кыз исеме
Джавахарлал ...
Татар осинасы
Садикта алар берничә адаш
«Әйтче, ...» җыры
Ул төкерсә, күл була
Питрәчтә хәрби уеннар
Рәссам Таша ...
«... гена күрсәм дә»
3 литрлы
Ельцин хатыны
...-ялангач
Су анасы югалткан
Итәкле кием
... Галилей
... Камский
Ялган яңалык
Тренер ... Капелло
Бигрәк тату кәҗә белән
Ди-джей ... Гыймадов
Бәрәңге тәгәрәтер өчен кирәк
«... бабай, әйлән давай!»
Жим
Дезодорант
...-Манш
... күтәреп ятмагыз
Европада ярымутрау
Сандугачка әмер
Йошкар-...
Кызарта торган хис
Әзәрбайҗан башкаласы
Язучы Тәүфикъ ...
Җырчы ... Токарев
Рәмиевләр газетасы
Үскәч, җиде була
«... хочет стать миллионером»
«Баунти» «пычкы чүбе»
... Садыйкова
Тутый кош токымы
«Минем исемем ...» О.Памук
Кояш тәңресе
Чаллы горурлыгы
Татарстан гимнын язган
Габделфәт җыры

Беләсең килсә...

1 Бу хәреф Америка Кушма Штатларының бер генә штат исемендә дә очрамый.
а) X;
б) Z;
в) Q.

2 Бу җирлектә «кар» төшенчәсен аңлатучы 421 сүз бар. Һәм бу факт рәсми рәвештә теркәлгән.
а) Гренландия;
б) Шотландия;
в) Аляска.

3 Хәйдәр Бигичев үзәк телевидениедә заманында нинди тапшыруда катнашкан?
а) «Утренняя почта»;
б) «Алло, мы ищем таланты!»;
в) «А ну-ка, парни!»

4 2014 елда Миннесотада Дэн Маккой исемле фермерда 3,8 килолы нинди гигант үсә?
а) алма;
б) помидор;
в) кыяр.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. б); 4 б).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 331

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+